УКЫТУЧЫ
Кайвакыт эти-әни хатасын да төзәтергә мәҗбүр...

> 4

ЯЛГЫЗ БАКШАНДЫ
«ВТ» хәбәрчесе кышын беркем дә яшәми торган авылны урап кайтты

> 5

##ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК
Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлекләре

> 7

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
Бу заманда ышандырмый торган ялган юк

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 147–148 (29114–29115) | Сишәмбе | 10 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАУРЫЙЛЫ КАГЫЙДӘ
КОШ ИТЕН САТУДА ТАЛӘПЛӘР КАТГЫЙЛАНДЫ

Авыл капкасы

Бәрәкәте булсын! Кош-корт итен базарда сатучылар өчен быелның 1 сентябреннән яңа кагыйдә үз көченә керде. Моннан ары сатылачак барлык кош-корт та махсус урында чалынырга тиеш. Кошчылык белән шөгыльләнүчеләр бу яңалыкны ничек кабул итте? Үзгәрешләр шәхси хуҗалыкларга ни дәрәҗәдә йогынты ясаячак? Без әлеге сорауларга ачыклык керттек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әлеге яңалык аяз көнне яшен суккандай булмады үзе. Матбугат чараларында узган елдан бирле хәбәр итеп килдек. Фермерларны да, кош-корт асраучыларның үзләрен дә алдан ук кисәттеләр. Шуңа да карамастан, Чистай районының Дүртөйле авылында яшәүче Гүзәлия Хәмәтгалимова күңелсез хәлдә кала язган. Аларның хуҗалыгында 1 мең баш кош-корт асрала. Каз-үрдәген, күркәсен, ярминкәдә сатарлык булсын дип, тырышып үстергәннәр.

– Беренче партия казларыбызны суеп эшкәрткәч, Казандагы ярминкәгә юл тоттык. Ул көнне кертсәләр дә, икенче атнада бары тик чалу цехы аша узган очракта гына рөхсәт буласын әйттеләр. Бик борчылган идек, чөнки районда бер генә чалу цехы да юк бит. Бәхеткә, җомга көнне Казаннан рөхсәт бирделәр. Ел ахырына кадәр тыныч күңел белән сатарга мөмкин булачак. Аннан соң нишләрбез – бернәрсә дә әйтә алмыйм, – диде ул.

Аның сүзләренчә, алга таба кош-кортны ничек тә махсус урында эшкәртү җаен карарга туры киләчәк.

– Районда кош-корт асраучылар шактый. Ләкин моңа кадәр сату белән авырлыклар булмагач, андый каршылыклар булыр дип уйламадык. Яшермим, безне бу турыда ярты ел элек кисәткәннәр иде инде. Ләкин алдан планлаштырганча, кош-кортларны барыбер сатып алдык. Махсус чалу урынын төзү безнең хәлдән килә торган гына эш түгел. Ул – зур чыгымнар сорый торган төзелеш. Аннан соң, безнең инде яшебез дә бар. Чебиләрне Мөслимдәге инкубатордан алып кайтабыз. Киләчәктә шунда ук чалдырып булмас микән дип тә уйлыйбыз. Ни уйларга да белгән юк. Бу эшебезне дә туктатасыбыз килми, – диде Гүзәлия Хәмәтгалимова.

Мөслим районында кошчылык белән шөгыльләнүче фермерлар да, шәхси хуҗалыклар да күп. Моннан берничә ел элек үк биредә кош-корт чалу цехы булдырылган иде. Тик әлеге цехта теләге булган барлык кеше дә кош-кортын чала алмый дип аңладык.

Әмәкәй авылында кошчылык белән шөгыльләнүче Ралинә Бәширова әйтүенчә, кошларны эшкәртү белән проблемалар юк.

– Узган ел Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе калдыкларны ташлый торган махсус чокырлар ясаттырды. Без аларны эшләдек. Фермадан чыккан калдык-постык, әшәкеләрне шунда җыябыз, яндырасын яндырабыз. Сатар алдыннан ветеринар кош түшкәләренә мөһер суга. Әлеге таләпләрне үтәгән очракта, проблемалар килеп туганы юк, – диде эшмәкәр ханым.

Күптәннән сөйләнсә дә, республикада моңа әзер түгелләр, чөнки күпчелек районнарда кош чалу цехлары юк. Билгеле булганча, моңа кадәр әлеге тәртип сарык, дуңгыз һәм мөгезле эре терлекләрне чалуга кертелгән иде инде. Терлекләрен сату өчен үстергән шәхси хуҗалыкларга да малларын махсус урыннарда чалырга туры киләчәк, дисәләр дә, әлегә катгый рәвештә таләп итү очраклары турында ишеткәнебез юк. Татарстанның Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов, сатуга дигән кош-кортны чалу тәртибе дә шулай салмак кына кереп китәчәк, дип ышандырды.

– Бу кагыйдәләрне бүгеннән, хәтта быелдан башлап кертү дә җиңел түгел, чөнки республикада кош суяр өчен җитәрлек сугым заллары юк. Без бу мәсьәлә буенча эш алып барабыз, әлбәттә. Эшмәкәрләр дә яңа сугым урыннары төзи башлады. Аларга зыян китермәс өчен, моңа ел дәвамында акрынлап, җайлап кереп китәрбез, – дип аңлатты Алмаз Хисаметдинов.

Буа районының Ташкичү авылы да күпләп каз асраучылары белән данлыклы. Биредә шәхси хуҗалыклар 200, 600, 800, хәтта 1 мең баш каз-үрдәк алып үстерә. Тик биредә яңа кагыйдәләр турында ишеткән-белгән кеше юк.

– Күп каз асрасак та, безнең базарга барып сатканыбыз юк. Инде ничә еллар дәвамында үз клиентларыбыз барлыкка килде. Өйдән генә алып китәләр яки илтеп бирәбез. Каклап та, ыслап та, чи килеш тә сатабыз. Күпчелегебездә зур катыргычлар бар, тиз арада сатылып бетмәгәнен шунда саклыйбыз. Безнең районда кош-корт өчен сугым заллары турында ишеткәнем дә юк. Булган очракта да, казларны ничек алып барасың анда? Күз алдыма да китермим. Бик мәшәкатьле эш булачак бит ул, – диде Салих Әхмәдуллин.

Әлегә шәхси хуҗалыкларга артык борчылырга туры килмәсә дә, кош түшкәләрен ярминкә, базар һәм кибетләргә куеп сатучылар өчен алдан хәстәрен күрми мөмкин түгел. Шуңа күрә киләчәктә кош чалу цехларын барлык районнарда төзү дә котылгысыз эш булачак.

Өйрәтәчәкләр

Татарстанда быел октябрьдән киләсе елның июнь аена кадәр өлкән сыйныф укучылары, училище һәм көллият студентлары өчен хәрби җыеннар уздырылачак. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән боерыкка кул куйган. Җыеннар яшь буынны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатыннан уздырыла. Документта әйтелгәнчә, җыеннар, закон нигезендә, белем алуның соңгы ике елында хәрби хезмәткә әзерләнергә тиешле яшь буын белән, «Тормыш иминлеге нигезләре» фәне кысасында уздырыла.

Моннан тыш 2024 елның апрелендә Казан танк училищесында кадет мәктәпләрендә унынчы сыйныфта укучылар белән 5 көнлек җыеннар үткәрү күздә тотыла.

Бу чарага сәламәтлеге мөмкинлек биргән барлык яшьләр җәлеп ителәчәк. Җыен алдыннан медицина тикшеренүләре үткәрәчәкләр. Ә инде нигезле сәбәп белән анда бармаучылар, теорияне өйрәнеп, зачет бирәчәк.

Кунак файдасы

Казанда туристлар сигез ай эчендә барлыгы 16,7 млрд сум акча тоткан. Бу – узган елдагыга караганда 59 процентка күбрәк. Туризмны үстерү буенча шәһәр комитеты директоры Дарья Санникова «СберАналитика» сервисы мәгълүматларына таянып әйтүенчә, шушы акчаның 24 проценты – кафе-рестораннарга, 22 проценты – азык-төлек кибетләренә, 21 проценты чамасы кунакханәләргә, төрле хезмәтләргә, күңел ачуларга сарыф ителгән.

Шәһәр мэры Илсур Метшин сүзләренә караганда, әлеге сан Татарстан башкаласының туристлык өлкәсен ни өчен бик актив төстә үстерүен аңларга ярдәм итә. «Туристлар 8 ай эчендә 16 миллиард сум сарыф иткән. Ә бит «Сбер» аша түләнгән сумма гына бу. 16 миллиард таксига, туристлык ширкәтләре, ресторан-кафе, кунакханәләргә генә түгел, шәһәргә дә киткән, чөнки әле салымнар да бар. Ә алар ярдәмендә без Казанны төзекләндерәбез», – ди мэр.

Көз үзенекен итә

Бу атнада республикада карлы яңгыр, һава температурасының «минус»ка төшүе, юлларда бозлавык көтелә. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 11 ноябрьдә көндез һава температурасы +2…+7 градустан артмаячак. Пәнҗешәмбе – 12 октябрьдә асылда көнчыгыш районнарда бераз гына явым-төшем булырга мөмкин. Көндез +3…+8, төнлә +1…–4 градус.

Синоптикларның башлангыч фаразлары буенча, җомга – 13 октябрьдә яңгырлы, җилле һава саклана. Шимбә – 14 октябрьдә җылырак: көндез һава температурасы +7…+12 градус чикләрендә тирбәләчәк. Урыны белән аз гына яңгыр көтелә.

Сәламәтлек

Җиде кат карап, бер кат кап

Россия халкы чит ил даруларының үзебездә җитештерелгән аналогларына өстенлек бирә башлаган. DSM Group агентлыгы мәгълүматларына караганда, ел башыннан бирле даруханәләрдә чит илдә чыгарылган 6,4 мең төрдәге дару сатылган. Бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 20,3 процентка азрак.

Бәйсез даруханәләр ассоциациясе башлыгы Виктория Преснякова фикеренчә, моңа чит илдә җитештерелгән даруларның кыйммәт булуы да йогынты ясаган.

Дөрес, үзебездә җитештерелгән даруларның файдасы юк, дип санаучылар да бар. Күпләр Россиядә җитештерелгән даруларга әле дә булса сагаеп карый. «Таттехмедфарм» оешмасы җитәкчесенең дарулар белән тәэмин итү буенча урынбасары Надия Шемякина моны ялгыш фикер дип саный. «Бөтен илләр дару җитештерү өчен кирәкле чималны Кытай белән Һиндстаннан ала. Шуңа күрә даруларны барыбыз да бер үк төрле җитештерә», – ди ул.

Гомуми практика табибы, медицина фәннәре кандидаты Флера Насыйбуллинага да бу сүзләрне еш ишетергә туры килә. Күпләр: «Үзебездә җитештерелгән аналог даруларны сатып алудан мәгънә бармы?» – дип кызыксына икән. Табиб сүзләренә караганда, дарулар һәм аларның аналоглары бер-берсеннән бәясе буенча гына аерыла. Файдасы да, тискәре йогынтысы да, нигездә, бер үк.

– Күпләр даруларның аналогларына шикләнеп карый. Арзанрак икән, димәк, сыйфаты да начаррак, дип фикер йөртә алар. Әмма аларның бәясе бу даруны уйлап тапкан башлангыч чордагы кебек ниндидер тикшеренү, тәҗрибәләр үткәрү өчен өстәмә чыгымнар тотылмаганга гына арзанрак була. Авырганда булышу-булышмавы ягыннан исә алар барысы да бер дәрәҗәдә, – ди табиб. – Дөрес, кайбер төр дарулар, күпме генә көтсәң дә, нәтиҗә бирмәскә мөмкин. Даруларны һәм аларның аналогларын составындагы төп матдә берләштерә. Әмма аларга кушылган ярдәмче матдәләр төрле булырга һәм организм аларны кабул итмәскә, моңарчы эчеп иярләнгән матдәне таләп итәргә мөмкин. Кайбер аналогларның шифасы тимәү әнә шуңа бәйле.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Дмитрий НОВИКОВ, Россия Дәүләт Думасы Халыкара эшләр буенча комитет рәисенең беренче урынбасары:

Мәктәп дәреслекләрен яңарту дәвам итә. Бу эштә совет педагогикасы казанышларын да, психология, заманча белем бирү алымнарын да берләштерергә кирәк. Әмма болар эчтәлеккә йогынты ясарга тиеш түгел. Белем бирүдә иң мөһиме – эчтәлек.

(КПРФ партиясе уздырган «түгәрәк өстәл»дә әйткән сүзләре)

РОССИЯДӘ – ТОРМЫШ МУЛЛЫГЫ

РИА «Новости» мәгълүмат агентлыгы Россия төбәкләренең тормыш муллыгы буенча рейтингын тәкъдим иткән. 2022 ел нәтиҗәләре буенча төзелгән исемлектә 100 балл белән бәяләнгән бердәнбер төбәк – Ямал-Ненец автономияле округы.

2022 ел нәтиҗәләре буенча урыны	Төбәк	Рейтинг баллары
1	Ямал-Ненец автономияле округы	100,00
2	Магадан өлкәсе	97,62
3	Ненец автономияле округы	93,29
...		
12	**Татарстан Республикасы**	**57,08**

Хәләл белән хәрам арасы

Татарстан Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты Свердловск өлкәсендә урнашкан ширкәттә тикшерү үткәрәчәк. Билгеле булганча, узган атнада Россельхознадзор белгечләре хәләл дип саналган колбасада дуңгыз ДНКсын тапкан иде.

«Реальное время» басмасы хәбәр итүенчә, хәләл ризык үрнәкләре һәр квартал саен лабораториягә тикшерүгә озатыла. Предприятиедә хәләл продукция өчен аерым җитештерү линиясе булдырылган. Контролерлар арасында дин әһеле дә бар. Тикшерелгән колбасаны җитештерелгән урыннан түгел, ә кибеттән алганнар. Ә анда хәләл һәм хәләл булмаган ризыкны урнаштыру һәм ташу кагыйдәләре үтәлмәскә дә мөмкин. Шул ук вакытта Россиядә хәләл ризык үрнәге алуны, лабораториядә тикшеренүләр үткәрүне җайга салучы ГОСТлар юк. Димәк, дуңгыз ДНКсы күзәнәкләре хәләл ризыкка очраклы гына да эләккән булырга мөмкин.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ӘЛЬ-АКСА ДАВЫЛЫ

Октябрь башы дәһшәтле вакыйгалар динамикасының көчәюе белән тарихка язылды. Якын Көнчыгышта вазгыять шулкадәр киеренкеләнде: Украина конфликты, тоныкланып, икенче планга күчте. Соңгы айларда Сүриядә хәлләр кискенләште.

Үткән атнада төрек хәрби көчләре Америка канаты астында хәрәкәт итүче Көрд Эшчеләр партиясе контролендәге төбәкләргә һөҗүмне көчәйтте. Моңа җавап итеп, американнар төрек беспилотнигын бәреп төшерде. Әнкара көтелмәгәнчә кискен реакция ясады: төбәктәге американнар файдалана торган нефть скважиналарын бомбага тотып яндырды. АКШ бушка талап ала торган майлы калҗадан колак какты диярлек. Төбәктәге конфликт төенен чишәргә дә өлгермәделәр, Фәләстыйн дөрләде: Газзә секторындагы ХАМАС сугышчылары, көтмәгәндә, сионистлар корган югары технологияле диварны җимереп, Израильгә һөҗүм иттеләр. Көз ачып йомганчы оккупация астындагы Ашкелон һәм Сдерот шәһәрләре боевиклар кулына күчте. Аз санлы сугышчан төркемнәр Газзә секторы территориясеннән зуррак булган төбәкне кулга төшерде. Вакыйгалар шундый тизлектә үсте ки, бу юллар авторы килгән хәбәрләрне тәртипкә салып өлгерә алмый иде.

Тел-Авивта да башта аңнарына килә алмый тордылар. Аннан соң моның гадәти вакыйга түгеллегенә һәркем төшенде. Халыкара җәмәгатьчелек – ил лидерлары һәм сәяси юлбашчылар вазгыятькә «тиңе булмаган» дигән бәя бирде. Һөҗүм итүче көчләр Көнбатыш лидерлары тарафыннан «террорчылар» дип бәяләнде, киеренкелекне туктатырга чакырулар яңгырады. Карабах вакыйгаларыннан соң Көнбатыш үзен оттыручы хәлендә тоя, Азәрбайҗанга каршы санкцияләр кертү омтылышлары да күп булды. Ачыктан-ачык антипатияләр билгеләнде: мөселманнарның хәрби уңышларына юл куярга ярамый иде. Фәләстыйн давылы (һөҗүм итүче көчләр аны «Әль-Акса давылы» дип исемләде. «Су басу» дип тәрҗемә итүчеләр дә бар) бик тиз һәм киң җәелде. Мөселманнар яшәгән дәүләт җитәкчеләре ике якны да киеренкелекне йомшартырга чакырды. Фәләстыйн гыйсъянчыларын бары тик Берләшкән Гарәп Әмирлекләре генә гаепләп чыкты. Мөселман илләрендә урамнар Фәләстыйнны яклаучылар белән тулды. Ил җитәкчеләре нинди генә позициядә тормасын, урам тавышына колак салмый кала алмый иде. Көнбатышта урамнар исә икегә бүленде. Бу юллар язылганда, Нью-Йоркта Израиль тарафдарлары белән Фәләстыйнны яклаучыларның кара-каршы килеп бәрелешүе турында хәбәр алынды.

Төрек лидеры Әрдоган, ниһаять, Фәләстыйн дәүләтен 1967 елгы чикләрдә торгызмыйча, мәсьәләне хәл итеп булмаячагы турында рәсми белдерү ясады. Израиль АКШтан хәрби ярдәм сорады. Аларның флоты Урта диңгезгә юл тотты инде. Әмма Гыйрак җиһадчылары, американнар сугышка кушылса, Америкага каршы ут ачачакларын белдерде. Вакыйгалар артларыннан куып җитмәслек дәрәҗәдә кызу һәм без темага әйләнеп кайтырга ниятлибез.

Россиядә

ЭШЧЕ КУЛЛАР ЭЗЛӘГӘНДӘ

Кремльдә «Әль-Акса давылы»на нейтраль мөнәсәбәт күрсәттеләр. Якын Көнчыгышта хәлләрнең кискенләшүе төшә башлаган нефть бәясен югары күтәрергә вәгъдә итә. Баррель дурт долларны өстәде инде. Мәскәү Карабах конфликтына да артык кушылып китмәде, сабырлык саклады. Украина белән конфликт та чабудан тота, маневрлар ясау мөмкинлеге чикләнгән. ХАМАС белән Мәскәү яхшы мөнәсәбәттә. Хәер, Израильнең дә Кремль белән элемтәсе начар түгел. Шулай булгач, кискен белдерүләр ясамау – иң отышлы юл.

Илнең эчке проблемалары кискенләшә. Бензин бәясен тотрыкландыру өчен, күпләр демпферны тулысынча кайтарырга туры килде. Хәзер нефть компанияләре бензин һәм солярканы эчке базарда саткан өчен дәүләттән тулы күләмдә компенсация алачак. Болай да очын очка ялгый алмаган бюджетка авыр булачак, әмма кая барасың? Илдә социаль шартларга юл куярга ярамый, моны яхшы аңлыйлар. Доллар яңа үрләр яуларга мөмкин, девальвация исә ике–өч айдан инфляция күтәрелешен вәгъдә итә. Мондый шартларда аяк астын бик карап атларга туры килә.

Эшче куллар проблемасы кискенләшкәннән-кискенләшә. Хезмәт базарында вакансияләр саны арта. Эшләргә кеше я бөтенләй юк, булганнары компетенциягә ия түгел. Җитештерүче автоматлаштырып һәм җитештерүчәнлекне арттырып, киеренкелекне йомшартып булыр иде – технологияләр һәм инвестицияләр җитешми. Россиядә моннан туксан ел элек Америкадан сатып алган станоклар эшләп утырган заводлар бар, диләр.

Өченче кварталда, 2022 елның шул чоры белән чагыштырганда, вакансияләр саны 2,3 тапкыр арткан. Персонал белән идарә итү тармагына хезмәткәрләр эзләү 3 тапкыр ук көчәйгән. IT тармак 2,8 тапкыр күбрәк кеше эзли, транспорт һәм логистика өлкәсендә буш урыннар 2,4 тапкыр күбрәк. Авыл хуҗалыгы, төзелеш, нефть чыгару тармаклары, сөрән салып, эшкә кеше эзли. Игътибар итсәгез, Урта Азия мигрантларын китертеп кенә, мәсьәлә хәл итерлек түгел, чөнки махсус белем һәм күнекмәләр таләп итүче вакансияләр өстенлек итә. Кадрлар кытлыгыннан җитештерүне кимететеп котылып була. Тик монысы да отышлы юл түгел.

ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ

Рәис көндәлеге

Башкалада Татарстанның яңа прокурорын тәкъдим иттеләр. Россия Президенты Указы нигезендә, киләсе биш елга бу вазыйфага Альберт Суяргулов билгеләнде.

tatarstan.ru

Яңа прокурор белән Россия Генераль прокурорының беренче урынбасары Анатолий Разинкин таныштырды. Альберт Суяргулов моңарчы Санкт-Петербург прокуроры урынбасары вазыйфасын башкарган.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан илнең терәк төбәге булып санала һәм ул традицион рәвештә социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләре буенча әйдәп бара.

– Уңай күрсәткечләргә ирешергә күпчелек очракта республиканың хокук саклау органнары, шул исәптән прокуратура белән уртак нәтиҗәле эшчәнлек ярдәм итә, – диде Рәис. – Ведомство хезмәткәрләренә тырышлык, фидакарьлек һәм һөнәри осталыклар өчен рәхмәт әйтәсем килә. Гражданнар һәм бизнесның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга бәйле күп кенә мәсьәләләр сезнең даими контрольдә тора. Прокурор ышанычлы яклаучы булырга тиеш. Илкүләм проектлар һәм республика программаларын тормышка ашыруда күзәтчелек итү игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Альберт Суяргулов сүзләренә караганда, аның һөнәри эшчәнлегенең төп максатлары үзгәрешсез, алар илебезгә һәм халыкка хезмәт итүдән гыйбарәт.

– Татарстан – күәтле икътисадый мөмкинлекләре, тарихи мирасы һәм төрле традицияләре булган төбәк. Әмма теләсә кайсы төбәкнең төп байлыгы ул – аның кешеләре. Республика ирешкән уңышларга караганда, аның халкын хезмәт сөючәнлек, үз дигәнендә нык торучанлык һәм алгарышка омтылыш аерып тора, – диде яңа билгеләнгән Татарстан Прокуроры. – Мин үз бурычларым итеп закон өстенлеген, гаделлекне, дәүләт белән җәмгыятьнең үзара һәм ихтирамлы мөнәсәбәтен булдыруны, Татарстанда яшәүче һәр кешенең хокуклары һәм иреген, шулай ук дәүләт мәнфәгатьләрен нәтиҗәле яклауны күрәм.

Суяргулов Альберт Зәки улы 1982 елда туган. Санкт-Петербург Хәрби-диңгез институтын һәм Санкт-Петербург дәүләт университетын тәмамлый. Прокуратура органнарындагы хезмәтен 2010 елда Ленинград өлкәсе прокуратурасының Всеволожск шәһәр прокуроры ярдәмчесе вазыйфасында башлый. 2022 елда Санкт-Петербург шәһәре прокуроры урынбасары вазыйфасына билгеләнә..

ИРТӘГӘСЕ БҮГЕН БАШЛАНА

Быел республикада мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты кебек 4 меңнән артык бина төзелә һәм төзекләндерелә. Бу хакта Татарстан Хөкүмәт йортында әйттеләр.

Министрлар Кабинетында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына Юлламасын гамәлгә ашыруга бәйле киңәшмә узды. Аны Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин үткәрде. Хөкүмәт җитәкчесе билгеләп үткәнчә, җыелышын фикер алыша торган документ ул – Татарстан Рәисе тарафыннан социаль-икътисадый үсешнең бу елга билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренең «генераль» планы.

– Ул республиканың тотрыклы үсешенә юнәлдерелгән һәм икътисад тармагы, социаль өлкәне генә колачлап калмыйча, гомумсәяси юнәлешләргә дә кагыла. Мәсәлән, гражданнарны идарә итүгә, Татарстанда яшәүче халыкларның мәдәниятләрен, телләрен һәм традицияләрен саклау процессына җәлеп итүне күздә тота. Безне Фәнни-технологик үсеш елы кысасында максатчан эш көтә, – диде Алексей Песошин.

Татарстан Премьер-министры сүзләренә караганда, икътисад өлкәсендә, сәнәгать һәм экспорт мөмкинлекләрен үстерү, агросәнәгать комплексы һәм эшкуарлыкны үстерү, аларга ярдәм итү белән беррәттән, икътисад тармакларын кадрлар белән тәэмин итү буенча да эш алып барылачак, тормышның барлык өлкәләрендә дә цифрлы технологияләрне кертү юнәлешендәге чаралар дәвам иттереләчәк.

– Планның социаль ягы, элеккечә, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният өлкәләрен үстерүгә юнәлдереләчәк. Патриотик тәрбия, хәрбиләрнең гаиләләренә ярдәм итү һәм Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерүгә аерым игътибар биреләчәк. Документны тормышка ашыру халыкара хезмәттәшлекне һәм эчке туризмны үстерүне дә күз уңында тота, – диде Хөкүмәт җитәкчесе.

Тәгаен эшләр турында Премьер-министр урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов сөйләде.

– Безнең төп бурыч – халыкның тормыш сыйфатын яхшырту, – диде ул. – Моның өчен Татарстанда илкүләм проектлар һәм республика программалары кысасында колачлы эш алып барыла. Быел социаль-мәдәни өлкәгә караган 4070 объект төзеләчәк, реконструкцияләнәчәк һәм төзекләндереләчәк. Бу – яңа мәктәпләр, балалар бакчалары, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт объектлары. 960 ишегалды, шулай ук иҗтимагый киңлекләр төзекләндерелә. Быел республикадагы 68 объектта эшләр тәмамланачак, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

АКМАСА ДА ТАМА

Кесә ягы яхшырган икән бит. Белгечләр әйтүенчә, соңгы егерме елда илдә иң күп һәм иң аз хезмәт хакы алып эшләүчеләр арасындагы «упкын» өч тапкыр кимегән. Моны, иң беренче чиратта, хезмәт өчен түләүнең минималь күрсәткечен арттыру белән аңлатканнар. Аз керемлеләр тагын да җиңелрәк сулап куймагае. 2025 елга кадәр кайбер төр пособиеләр икеләтә артачак дип фаразлана. Киләсе елда булачак пенсия күләме дә билгеле.

Бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты белгечләре исәпләп чыгарган: быел илдә иң югары һәм иң түбән уртача хезмәт хаклары бер-берсеннән 13,1 тапкыр аерыла. Чагыштыру өчен, 2001 елда әлеге күрсәткеч – 40ны, 2005 елда исә 24,9ны тәшкил иткән. Әлеге күрсәткеч алга таба да кимүен дәвам итәчәк, дип тә фаразлаганнар. Беренчедән, хезмәт өчен түләүнең минималь күләме даими арта. Россия Президенты Владимир Путин чыгышларының берсендә, киләсе елның 1 гыйнварыннан әлеге күрсәткеч, 18,5 процентка үсеп, 19242 сумга җитәчәк, дип белдерде. Илбашы сүзләренә караганда, әлеге яңалык 4,8 миллион эшчегә кагылачак. Быел исә хезмәт өчен түләүнең минималь күләме 6,3 процентка артты һәм 16 мең 242 сум тәшкил итте.

– Бүген хезмәт базарында төзелеш, җитештерү, транспорт кебек тармаклар өчен кирәкле эшче көчләргә кытлык зур. Аларга лаеклы хезмәт хакы да вәгъдә итәләр. Әле яңа бер игъланга күзем төште, төзелеш оешмасына аена 80 мең сум хезмәт хакына эретеп ябыштыручы эзлиләр. Мондый тәкъдимнәр җитәрлек. «Ак яка»лы юрист, финансистлар заманы артта калып бара, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Шунысын да әйтергә кирәк: җәмгыятьтә «соры» хезмәт хакы алып эшләүчеләр кимегәннән-кими. Чөнки халык алдагы көн турында күбрәк уйлана.

Киләчәк дигәннән, 2024 елда пенсионерларның кипме акча алачагын да әйткәннәр. Илнең финанс министры Антон Силуанов сүзләренә караганда, 2024 елда лаеклы ялдагыларга түләүләр инфляция күрсәткече дәрәҗәсендә, ягъни 7,5 процентка артачак. Киләсе елның 1 гыйнварыннан эшләмәүче пенсионерларның уртача пенсиясе 23244 сум тәшкил итәчәк, дип көтелә. Рәсми саннарга караганда, 2024 елда пенсия түләүгә генә дә 10 триллион сумнан артык акча тотылачак.

Пособиеләр дә арта. 2025 елга кадәр әлеге төр түләүләрнең кайберләре икеләтә күтәреләчәк, ди әнә. Аерым алганда, ике елдан вакытлыча эшкә яраксызлык буенча түләү күләме хәзерге 2,7 мең сумнан 5,7 мең сумга кадәр җитәчәк, дигәннәр илнең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгында. Киләсе елда исә әлеге күрсәткеч 4,1 мең сум булачак.

Исегезгә төшерәбез: пособие күләме иминият стажына бәйле. Әгәр иминият стажы 5 елдан да азрак икән, хезмәткәр авырып китү сәбәпле, аңа алдагы ике еллык уртача хезмәт хакының 60 проценты, 5–8 ел булса – 80 проценты, 8 елдан күбрәк булса, 100 проценты күләмендә акча түләнә.

Бала тапкан һәм тәрбияләгән өчен пособиеләр дә артачак. Шул ук чыганаклардан алынган мәгълүматларга караганда, киләсе елда йөклелек һәм бала табу буенча дәүләт ярдәменең максималь күләме 565 мең сумга (быел ул 383 мең сум чамасы) җитәчәк. Ә 2025 елда әлеге күрсәткеч 794 мең сумлык чикне узар, дип фаразлана. Яшь ярымга кадәр бала тәрбияләгән өчен пособиенең максималь күләме дә ике елда быелгы 33 мең сумнан 69 мең сумга җитәчәк, дип вәгъдә иткәннәр. Шунысын да истә тотыгыз: әлеге төр түләүләр соңгы ике елда алган уртача хезмәт хакына бәйле. Белгечләр әйтүенчә, пособиеләрнең максималь күләме арту агымдагы елның 1 гыйнварыннан иминият кертемнәренең бердәм тарифы гамәлгә керүгә бәйле. Артуы хак булсын.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Җиде кат карап, бер кат кап

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Башкаладагы даруханәләрнең берсендә провизор булып эшләүче Регина Хәбибуллина сүзләренчә, күпләр шикләнеп караса да, соңгы арада халык күбрәк даруларның үзебездә җитештерелгәненә өстенлек бирә башлаган.

– Санкцияләр аркасында киштәләрдән күп кенә дарулар юкка чыккач, күпләр аларны сорап аптыраттыс, үзебездә җитештерелгән аналогларын тәкъдим иткәч, «юк» дип кырт кисәләр иде. Хәзер исә, киресенчә, башта ук даруның аналогын сорап килүчеләр бар. Бу, иң беренче чиратта, кесә ягына бәйледер, дип саныйм. Халыкны аналог даруларның файдасыннан бигрәк арзан булуы кызыктыра. Бар нәрсәгә бәя арткан, халыкның кесәмнәре исә кимегән көннәрдә моңа аптырыйсы юк, – ди ул.

Аналог даруларның файдасы юк, дигән фикер белән дә килешеп бетми Регина Хәбибуллина. «Теләсә кайсы препаратның кешегә ни дәрәҗәдә ярдәм итүе аны кайчан ничек эчүгә, дөрес итеп саклауга да бәйле», – ди провизор.

Саклау дигәндә, соңгы арада ил халкы итәк-җиңнәрен җыеп, акчаны саграк тота башлаган. Күпләр хәтта даруларга дигән чыгымнарын да киметергә мәҗбүр булган. Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге тарафыннан уздырылган сораштыруда респондентларның 68 проценты дарулларга дигән чыгымнарны киметүен – иң кирәкле һәм иң очсыз даруларны гына ала башлавын әйткән. Шул ук сораштырудан аңлашылганча, ил халкының өчтән бере (34 процент) даруларга ай саен 2 мең сумнан артык акча сарыф итә икән. Респондентларның 7 проценты исә бу максатта ай саен 5 мең сум акча тотуын әйткән.

Рәсми саннарга караганда, яшәү өчен мөһим булган дарулар ел башыннан бирле уртача 1,9 процентка кыйммәтләнгән. Вирусны авырулар котырган чорга аяк баскач, даруларга ихтыяҗ да арткан. Әйтик, сентябрь башында сулыш юлы авыруларын дәвалау өчен кулланылган дарулар 66 процентка күбрәк сатылган. «Продажи.рф» аналитик статистика үзәге белгечләре шулай ди. Көз җитү белән, даруханәләрдә битлекләр дә күпләп сатыла башлаган. Тәгаенрәк әйтсәк, сентябрь башыннан ил халкы даруханәләрдән 1,3 миллион сумлык, барлыгы 46 мең кап битлек сатып алган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүз уңаеннан

Мәскәү дәүләт университеты студентлары өйдәге дарулар тартмасындагы препаратларны тикшереп торучы махсус мобиль кушымта эшләгән. Проект җитәкчесе Софья Рудеева сүзләренә караганда, бу кушымтага өйдәге дару турында бар мәгълүмат (яраклылык вакыты, нәрсәдән дәвалавы, аллергия китереп чыгару-чыгармавы һ.б.) туплана. Шул ук кушымта кешегә кул астындагы кайсы даруның бетүе, яраклылык вакыты чыгу турында да искә төшереп торачак. Әлегә сынау рәвешендә файдаланучы әлеге кушымтаны якын киләчәктә бөтен ил күләмендә таратырга җыеналар.

«БАШКАЛАРГА ИКЕНЧЕ СОРТЛЫ ИТЕП КАРАУДАН ТУКТАРГА КИРӘК»

РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ «ВАЛДАЙ» ФОРУМЫНДА ЧЫГЫШЫ НӘРСӘ БЕЛӘН ИСТӘ КАЛДЫ?

Күптән түгел Россия Президенты Владимир Путин Сочидагы «Валдай» халыкара дискуссия клубының пленар утырышында чыгыш ясады. Россия икътисады, махсус хәрби операция, XXI гасырда халыкара мөнәсәбәтләр корылышы нинди булырга тиеш – дәүләт башлыгы үз чыгышында әнә шуларга игътибар юнәлтте. «Кешелек яңа каршылыкка түгел, ә дәүләтләр һәм цивилизацияләрнең синергиясенә (үзара хезмәттәшлек итүенә) таба йөз тота. Асылда, Россия алдында яңа дөнья төзү бурычы тора», – диде.

kremlin.ru

КӨНБАТЫШНЫҢ СӘЯСИ КУРСЫ ТУРЫНДА

Кешелекнең глобаль проблемалары чишелешне уртага салып табуны таләп итә, ә менә эгоизм юньлегә илтмәячәк. 20 ел элек шушы дискуссия клубы утырышында очрашканда, безнең илебез авыр чор кичерә иде. СССР таркалганнан соң, Россия шактый авыр юл узды. Без бар көчебез һәм изге ниятләр белән гадел дөнья корылышын төзү процессына кушылдык. Кайберәүләр бу омтылышны дөрес аңламады. <…> Көнбатышның иминлеге гасырлар дәвамында колонияләрне талау хисабына ирешелгән. Бу – факт. Хәрби-финанс пирамидасы – Көнбатышның дөньяга тәэсире әнә шул.

АЛТЫ КАГЫЙДӘ

XXI гасырда халыкара мөнәсәбәтләр төп алты принципка нигезләнергә тиеш.

Беренчесе – ачык дөнья. Без ачык, үзара бәйләнештә булган дөньяда яшәргә телибез.

Икенчесе – цивилизацияләр төрлелеге. Илне яки халыкны ничек яшәргә, үзләрен ничек хис итәргә өйрәтү тыелырга тиеш.

Өченчесе – уртак карарлар. Киләчәк дөнья – күмәк карарлар булган дөнья. Берәү генә барысы өчен дә берни хәл итми.

Дүртенчесе – гомуми иминлек һәм тотрыклы дөнья. Горурлыктан, тәкәбберлектән баш тартырга, башкаларга икенче сортлы партнерлар итеп караудан туктарга кирәк.

Бишенчесе – гаделлек.

Алтынчысы – тигез хокуклар.

УКРАИНАДАГЫ НИЗАГ ТУРЫНДА

Көнбатышның билгеле бер өлешенә һәрвакыт дошман кирәк. Стратегик фикерләү урынына кыска вакытлы, үз файдасын гына эзләүче мәнфәгатьләргә иярү бара.

Бер генә тапкыр әйтелмәде инде: без Украинага каршы сугыш башламадык, без, киресенчә, аны туктатырга телибез. Украинадагы низаг – җирле низаг кына түгел. Безнең гамәлләр, беренче чиратта, кешеләрне һәм үз гореф-гадәтләребезне яклау максатына бәйле.

Россия – территориясе буенча дөньядагы иң зур ил. Бездә башка территорияләрне яулап алу максаты юк. Безгә әле үзебезнең Себерне, Көнчыгыш Себерне, Ерак Көнчыгышны үзләштерәсе дә үзләштерәсе.

РОССИЯ ИКЪТИСАДЫ ТУРЫНДА

III квартал нәтиҗәләре буенча профицит күзәтелде, ә быел һәм 2024–2025 еллар нәтиҗәләре буенча 1 процент тирәсе дефицит көтелә. Бездә эшсезлек күрсәткече рекордлы дәрәҗәдә түбән. Нефть һәм газдан керемнәр кимеде, әмма моңа да карамастан, алар да плюста (+3%). Нефть һәм газ булмаганнары, ягъни эшкәртү сәнәгате дә шулай ук (+43%).

Гомумән, бездә тотрыклы вазгыять, безгә каршы санкцияләр кертелгәннән соң барлык проблемаларны җиңдек һәм яңача үсеш этабын башладык.

Бездә оборона чыгымнары артты, әмма оборона өчен генә түгел, ә оборона һәм иминлек өчен. Алар ике тапкыр артты. Әмма без барысын да тупларга сарыф итәбез дә май турында онытабыз дигән сүз түгел бу.

РОССИЯНЕҢ БӨЕКЛЕГЕ ТУРЫНДА

Беләсезме, бүген Россиянең бөеклеге аның суверенитетын ныгытудан гыйбарәт, ә суверенитет технологияләрдә, финансларда, гомумән икътисадта, оборона һәм иминлек өлкәсендә үз-үзеңне тәэмин итүгә нигезләнергә тиеш. Бүгенге Россия белән ни өчендер көрәшә башлаган кешеләрне аңламыйм. Бәлки, ахмаклык аркасында гынадыр.

Фараз

Санауның артыгы юк

2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектын Дәүләт Советына тапшырдылар. Якын арада документны профильле комитетларда тикшерәчәкләр, аннары парламентта аның буенча фикер алышу башланачак.

– Хәзер депутатлар бюджет турында закон проектын өйрәнә, – диде Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин. – Алдагы еллардагы кебек үк, бюджетның керем өлешен арттырабыз. 2024 елда асылда 40 миллиард сумга арта ул. Шулай ук чыгым өлеше дә зурая.

Комитет башлыгы билгеләп үткәнчә, бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре федераль дәрәҗәдә билгеләнгән. Болар – махсус хәрби операциягә, социаль мәсьәләләрне хәл итүгә, сәнәгатьне технологик яктан яңарту, инновацион проектларны тормышка ашыруга бәйле бурычлар. Узган атнада бу хакта Федерация Советында бюджет буенча үткәрелгән парламент тыңлауларында да сөйләштеләр. Шулай ук федераль һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру да үзгәрешсез кала.

Леонид Якунин парламентка кертелгән 2024 ел бюджеты проектын «оптималь» дип бәяләде. «Агымдагы елда тагын нәрсәләргә игътибар итәргә икәнен карарга кирәк, – диде ул. – Хәлләр киеренке булып кала, чөнки санкцияләрнең йогынтысы дәвам итә. Әмма, әйтергә кирәк, сәнәгать эшли. Планлаштырылган керемнәргә карап фикер йөртсәк, алдагы өч елга кулай фараз төзелгән. Чыгымнар керемнәр белән тәэмин ителәчәк, дефицитның кинәт үсүе көтелми». Якунин сүзләренә караганда, быел керемнәр планда каралганнан алданрак та керә икән.

2024 елга төзелгән бюджет, алдагы еллардагы кебек үк, социаль юнәлешле булып кала. «Барлык социаль мәсьәләләрне хәл итүгә акча табылачак, республика программаларын тормышка ашыру дәвам итәчәк, – диде Леонид Якунин. – Бүген без бюджетны программалар буенча төзүнең республиканы үстерү өчен иң нәтиҗәле юл булып торуына инандык. Чыгымнарның 90 проценттан күбрәге программаларга кертелгән».

Татарстан Республикасы Рәисе керткән бюджет турында закон проекты ике телдә – рус һәм татар телләрендә әзерләнгән. Документ барлыгы 4934 биттән тора.

19 октябрьдә Дәүләт Советында парламент тыңлаулары үткәреләчәк. Моңа кадәр 17 октябрьдә муниципалитетлар белән видеоконференция режимында республика киңәшмәсе үткәрелергә тиеш. 24 октябрьгә кадәр республиканың төп финанс законын парламентның барлык профильле комитетларында карап тикшерү, шуннан соң Бюджет, салым һәм финанс комитетында аңа гомуми бәя бирү күздә тотыла. Соңыннан закон проекты өч укылышта каралачак.

2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына Татарстан бюджеты турында закон проекты, теркәлгәннән соң, Дәүләт Советының рәсми сайтына урнаштырылачак.

Яңалык

ИКЕЛӘТӘ ИСӘПЛӘНӘЧӘК

Контракт буенча хезмәт итүчеләргә гражданлык пенсиясен билгеләгәндә ташлама каралган.

– Сүз махсус хәрби операциядә катнашкан чорда икеләтә күләмдә стаж исәпләнү һәм 3,6 югары пенсия коэффициенты кулланылу турында бара, – дип ачыклык кертте Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин. – Махсус хәрби операциядә катнашкан чор зур стаж өчен вакытыннан алда иминият пенсиясе билгеләгәндә дә исәпкә алыначак.

Ягъни бу – контракт буенча хезмәт итүчеләргә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукы гомуми билгеләнгән таләпләр нигезендә пенсиягә чыгу яшеннән ике елга иртәрәк бирелергә мөмкин дигән сүз. Тик шунысы да бар: ир-атларга – 60 яшь, ә хатын-кызларга 55 яшь тулган булырга тиеш. Әлеге төр ташламадан 42 ел иминият стажы булган ир-атлар һәм 37 ел иминият стажы булган хатын-кызлар файдалана ала.

– Иреклеләр хәрәкәтләрендә катнашкан вакытта авыру яки имгәнү аркасында инвалидлык алучыларга искәрмә бар. Бу очракта хәрби хәрәкәтләр зонасына үз теләге белән китүчегә дәүләт пенсиясе белән тәэмин ителеш буенча инвалидлык нигезендә пенсия билгеләнә, – дип тә ассызыклады Эдуард Вафин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Аерым алганда, беренче төркем инвалидлар – 21,4 мең сум, икенче төркем инвалидлар – 17,8 мең сум, ә өченче төркем инвалидлар 12,5 мең сум күләмендә пенсия ала. Әгәр үз теләге белән хәрби хезмәттә катнашучы кеше 18 яшькә кадәрге яки техникумда яисә югары уку йортының көндезге бүлегендә укучы 23 яшькә кадәрге бала тәрбияләсә, пенсия күләме артачак. Өстәмә акча инвалидлык буенча билгеләнгән пенсия күләменнән чыгып билгеләнә, әмма тәрбиядә торучылар саны өч кешедән дә күбрәк була алмый.

Шунысын да искәртик: хәрби хезмәткәрләргә гражданлык пенсиясен, тиешле яшькә җиткәч, Социаль фонд билгели. Лаеклы ялга иртәрәк чыгучыларга исә түләүләрне хезмәт итү урыны буенча кадрлар бүлегендә билгелиләр.

Федераль канун нигезендә, 2023 елда хәрби пенсионерларга картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенә хокук берничә шарт үтәлгәндә бирелә.

– Беренчедән, иминият стажы – 14 елдан, ә шәхси пенсия коэффициенты 25,8дән дә ким булмаска тиеш. Икенчедән, хәрби хезмәткәр пенсия яшенә җитәргә тиеш. Быел, күчеш чорын исәпкә алып, хатын-кызлар өчен ул – 56,5 яшь, ир-атлар өчен исә 61,5 яшьне тәшкил итә, – диде Эдуард Вафин.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Хокукый ярдәм

Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә бушлай юридик ярдәм дә күрсәтелә. Белгечләргә бушлай мөрәҗәгать итү хокукына мобилизациягә чакырылучылар, контракт буенча хезмәт итүчеләр, хәрби хәрәкәтләр зонасына үз теләге белән китүчеләр һәм аларның гаилә әгъзалары ия, дип искәртте Татарстан юстиция министры Рөстәм Заһидуллин.

Бушлай юридик ярдәм алу өчен **222-60-60** кайнар линиясенә шалтыратырга кирәк. Гражданнарны Татарстан Юстиция министрлыгы бинасында кабул итәләр.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе контроль һәм коррупциягә каршы эш идарәсенең муниципаль эшчәнлеккә һәм оештыру-күрсәтмә документларның үтәлешенә контроль бүлеге баш белгече **Бойкова** Лариса Николаевна, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе эшләр идарәсенең финанслар, смета-шартнамә бүлеге башлыгы **Вострова** Ирина Валентиновна, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлеге баш белгече **Вьюрова** Лариса Юрьевна, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы **Сафиуллина** Лилия Рәшит кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «ТАНЕКО» акционер җәмгыятенең «Нефть-газ эшкәртү» бизнес-юнәлеше протоколны оештыру, эш башкару һәм үтәлешне контрольдә тоту бүлеге башлыгы урынбасары **Исхакова** Лилия Фәрит кызы, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте Нефть һәм нефть продуктларын сату идарәсенең баланслар, нефть һәм нефть продуктларын эчке базарда сату бүлеге башлыгы урынбасары **Мәрданшин** Вадим Әнәс улы, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Бизнеска хезмәт күрсәтү үзәге директоры **Павлов** Рөстәм Реннат улы, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте Нефть һәм нефть продуктларын сату идарәсенең нефть һәм нефть продуктларын экспортлау бүлеге әйдәүче инженеры **Шугаева** Татьяна Алексеевна **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

***

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте Нефть һәм нефть продуктларын сату идарәсенең баланслар, нефть һәм нефть продуктларын эчке базарда сату бүлеге башлыгы **Агапов** Валерий Николаевичка, «Геотех-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте әйдәүче технологы **Камалтдинов** Ривгать Рәшит улына **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Яңа заман – яңа империя

Шушы ай башында испан шәһәре Гренадада узган саммитта Европа берлегенә кергән илләрнең дәүләт һәм хөкүмәт башлыклары берлекне тагын да киңәйтү мәсьәләләрен карады. Евросоюз дәүләтләренә яңа әгъзаларны кабул итәргә, алар белән хезмәттәшлеккә әзер торырга кушылды. Якын елларда берлектәге илләр саны 30дан артып китәчәк, дип исәпләнелә…

Кешелек тарихына карасак, анда теге яки бу дәверләрдә яшәгән дистәләгән империяләрне күрәбез. Нихәл итәсең, бар булган тарих – сугышлар, яулап алулар тарихы. Кемдер корал көче ярдәмендә башка илләрне, кавемнәрне буйсындырып, барысы өстендә дә торган, халыклар, гади кеше мәнфәгатьләре белән артык исәпләшмәгән гөнаһлы берләшмәләр тудырган. Антик чорлардан алып XX гасырга чаклы шулай барган. Тик менә яши-яши шуңа җиттек: империянең гел башка кимәлдәгеләре дә яралды һәм яши. Яши генә түгел, зурая да. Европада без бүген күп халыкларны бер түбә астына җыя, яңа төр бәйләнешләр тудыра алган, үз парламенты, законнары, башкарма органнары, суды, хәтта Хисап палатасы һәм Үзәк банкы булган, Евросоюз дип аталган алагаем империяне күрәбез. Сәер империяне. Сәерлек шунда: ул империягә керәсең килсә, керә алсаң – керәсең. Чыгасың бик килә икән, рәхим ит, чык, сине беркем дә тотмый, сепаратизмда гаепләми.

Европа берлеге, яңа төр империя, дигәндә, «Моңа чаклы аерым яшәгән, мөстәкыйль икътисадый сәясәт алып барган дәүләтләргә анда ни калган соң?» – дигән сорау да туа. Ник анда керү өчен чират? Ник теләгән бер дәүләтне ул берлеккә алмыйлар? Алмыйлар, чөнки билгеле бер таләпләр үтәлергә тиеш: көндәшлеккә сәләтле базар икътисады, хокукый җәмгыять, ирек-хөрлек, кеше хокуклары тулысынча үтәлү һәм башкалар. Шартлар арасында әле тагын азчылыкларны яклау дигән пункт барлыгы да мәгълүм.

Евроимпериянең классик империя белән уртаклыгы шунда: күпсанлы милләт, халыклар бер түбә астында яши, бергә хуҗалык итә. Территориаль зурлык та аны тарихи империяләргә охшата. Аермаларга килгәндә, алары күбрәк. Яңа төр империядә, аңлавыбызча, рәхәттә йөзгән метрополиядә, аны ашаткан, эчерткән, даими күңелен күреп торган, ә үзе ничек булдыра ала – шулай җан асраган колонияләр юк. Тигез горизонталь мөнәсәбәтләр, тигез хокуклар, тигез мөмкинлекләр. Рациональ хуҗалык алып бару, интеграция өчен оешкан уртак базар, уртак дип әйтерлек җитештерү, бергә тормышка ашырылучы проектлар, чикләрнең шартлылыгы, пошлиналарсыз товар ташулар, виза ачмый гына бер-беренә «кунакка йөрүләр». Иске дөньяның җәмгысы 500 миллионнан артык халкы яшәгән, 27 дәүләтне сыйдырган, дөньяви тулай эчке продуктның чиреген җитештереп килгән менә шундый заманча империя.

Теләгән һәркемне алмыйлар, дидек. Әйтик, Төркия инде егерме елдан артык ЕС ишеген шакый. Әлегә ачучы юк. Әрдоган, елга берничә тапкыр Европа ягына карап, үпкәсен белдерә. Тик кабул итәргә ашыкмыйлар. Сәбәпләренә килгәндә, Төркиянең төрки дәүләт, мөселман иле булуы, биләмәләренең бик аз өлешенең генә Европа кыйтгасына урнашуын әйтү урынлыдыр. Башкасы да бар: күпләр танымаган Төньяк Кипр төрек дәүләтен даими яклау, кеше хокуклары торышы канәгатьләнерлек булмау, азчылыкларны (мәсәлән, көрдләрне) кыерсыту.

Якын араларда Европа берлегенә элекке Югославия республикалары булган дүрт дәүләт – Сербия, Черногория, Македония, Босния-Герцеговина һәм Албания керергә мөмкин. Ә менә кандидатлыкта йөргән Молдавия, Украинаның шанслары зурдан түгел. Молдавия Приднестровье дип аталган гаугалы территория аркасында калып килә, Украина дигәндә, гомумән, аңлатмалар артык. Әлегә кандидат саналмасалар да, тагын берлеккә гариза язган Грузия белән Косово да бар. Тик Сербиядән аерылып башка чыккан Косовоны дөньяның 60тан артык иле һаман танымый. Грузия исә Европадан ерактарак. Шунысын да искәртик: Европа берлеге дип аталган «колхоз»га кыйтгада яшәп картайган, тик һаман анда кермәгән дәүләтләр дә юк түгел. Швейцария белән Норвегиянең анда ни өчендер керәсе килми. Үзсүзле инглизләр (Бөекбритания) исә аннан 2020 елны чыкты.

Тик аерылганны аю ашар, дигән кебек, аерымланып яшәү бүгенге шартларда икътисадый яктан бер дә отышлы түгел. Аерымланып яшәү ул – чикләр, берең җитештергәнне икенчең кабатлау, бер-береңдә олы дипмиссияләр тоту, капитал, товар йөрешенә каршы киртәләр, валюталар төрлелеге. Кыскасы, бик үк акланмаган чыгымнар. Берлеккә кергән тәкъдирдә, икътисадый яктан кендекләр кендеккә береккән булса да, сәяси яктан һәр дәүләт суверен, ирекле кала. Элеккеге империяләрдән төп аерма ихтимал шулдыр.

XXI гасырда, Евросоюз кебек империягә кермәгән җәһәттә дә, үз кабырчыгына гына посып яшәгән дәүләтләр гомумән дә юк кебек. Абсолют суверенлык – үткән заманнар рудименты. Башка кыйтгалардагы илләрдә дә Европа үрнәгендә берләшү уе юк түгел. Шул җөмләдән, хәтерләсәк, СССР таркалыр алдыннан яңартылган берлек – Суверен республикалар берлеге дип аталган, Татарстаныбызга да тулы хокуклы субъект статусы вәгъдә иткән икътисадый империя төзү планы бар иде. Ниятне, белүебезчә, ГКЧП дигән фетнә юкка чыгарды. Бүгенгә кайтсак, Россия, Казахстан, Белоруссия кергән Таможня берлеге дә – икътисадый берләшүнең бер формасы. Пошлинасыз сәүдә, таможня кануннарының бертөрлелеге, продукцияне сертификацияләүгә бер үк таләпләр.

Сүз ахырында шуны да әйтәсе килә: Россиягә дә Европа берлегенә кергәндә бер дә начар булмас иде кебек. Тик Брюссель куячак шартларны үтәү әлегә мөмкин түгел. Икътисадыбыз әлегә тулысынча көндәшлеккә корылмаган. Берлек бездәге ирек-хөрлекне, кеше хокуклары яклануны да үзенчә бәяләячәк. Кыскасы, ул монастырь уставы әлегә безгә туры килеп бетми.

РӘХМӘТЛЕ БУЛЫЙК

Мәгариф

Татарстан укытучылары фәнне тормышка бәйләп аңлата, балалар белән уртак тел таба белә. Аларның «иң-иң»нәрен «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә узган Халыкара укытучылар көнендә бүләкләделәр. Тантанада Рәис Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. «ВТ» хәбәрчесе укытучыларның кәефен белеште.

tatarstan.ru

– Республика укытучылары ел саен федераль дәрәҗәдә таныла. Укучылар исә бөтенроссия олимпиадасында җиңүчеләр, призерлар саны буенча – өченче урында. Без һәрберегезнең уңышы белән горурланабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов бәйрәм тантанасында.

Рөстәм Миңнеханов белдергәнчә, Татарстанда мәгариф тармагында матди-техник базаны үстерү, мәгариф сыйфатын, педагогларның хезмәт абруен күтәрүгә аерым игътибар бирелә. Россиядә игълан ителгән Укытучылар һәм остазлар елы – укытучыларга рәхмәт сүзләрен җиткерү өчен тагын бер сәбәп.

Кемнәр алар – укытучыларның иң яхшысы, каймагы? Иннополис лицееның математика укытучысы Арман Костанян быел «Ел укытучысы – 2023» бөтенроссия конкурсында беренче бишлеккә керде. Иннополис мәктәбе укытучысы Юлия Тихонова «Беренче укытучы» бөтенроссия конкурсы лауреаты булып танылды. Казандагы 41 нче бакча тәрбиячесе Айсылу Лотфуллина «Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы» конкурсында мәктәпкәчә белем бирү юнәлешендә җиңү яулады. Башкалабызның 13 нче гимназиясендә татар теле һәм әдәбият укыткан Алинә Шәгәрәева әлеге конкурста иң яхшы биш укытучының берсе булды. Казанның 101 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Юлия Токмакова «Россиянең Ел тәрбиячесе – 2023» бөтенроссия һөнәри конкурсының топ-бишлегенә керде. Татарстан мәгариф һәм фән министры аларны республиканың, илнең горурлыгы дип атады.

28 яшьлек Арман Костанян Югары Ослан районының Иннополис мәктәбендә математика укыта. Аның укучылары халыкара, бөтенроссия олимпиадаларында җиңү яулый. Кайберләре үзләре дә укытучы һөнәрен сайлаган.

«Ел укытучысы» республика бәйгесендә җиңү яулагач, Арман Костанян турында язып чыккан идек. Мәктәпкә очраклы гына килгән ул. Аңа кадәр программист булып эшләгән, КВНда уйнаган. Хәзер мәктәптә алтынчы елын укыта. Әллә нинди кызыклы алымнар уйлап таба. Дәресләрен рэп стилендә дә тәкъдим итә, кирәк икән, фортепианода да уйнап җибәрә. Илкүләм бәйгенең мастер-классында геометриянең шигърият белән бәйләнешен күрсәткән.

– Математиканы тормышта әйләнә-тирәдәге теләсә кайсы предметка бәйләп аңлатырга тырышам. Әйтик, ул ишек, дивар, шешә, кәстрүл капкачы, сыр кисәге… – теләсә нәрсә булырга мөмкин. Замана тиз үзгәрә. Шуңа күрә фәнне тәҗрибә, фикер алышу юлы белән өйрәтү отышлы дип саныйм, – ди Арман Костанян.

Укучының күңеленә ачкыч табарга ясалма интеллект та ярдәм итә. Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцовка Арман шул хакта сөйләгән. Укытучы фикеренчә, ясалма интеллектка башта гади, аннан катлаулырак сораулар биреп, һәр баланың укудагы сәләтен, аның йомшак якларын ачыкларга мөмкин. Шуның нәтиҗәсендә укытучы һәр бала белән аерым эшли ала.

Алинә Шәгәрәевага исә тантанада «Татарстанның атказанган укытучысы» исеме бирелде.

– Укытучылар бәйрәмендә бу исемне алу минем өчен иң зур бүләк булды. Хезмәтемне шулай югары бәяләүләре өчен чиксез рәхмәтлемен. Бу – бик зур дәрәҗә һәм шул ук вакытта зур җаваплылык та. Бирелгән исемне аклап, тагын да зуррак уңышларга ирешеп, исән-сау эшләргә насыйп булсын иде, – диде Алинә Шәгәрәева.

Аның әйтүенчә, Укытучылар һәм остазлар елында республика хөкүмәте тарафыннан мәгариф өлкәсенә зур ярдәм күрсәтелгән. Укытучы һөнәренең абруен күтәрү, яшь белгечләрне җәлеп итү өчен, бик күп эшләр башкарылган. «Укытучыларга мактаулы исемнәр һәм дәүләт бүләкләре дә быел гадәттәгедән юмартрак бирелде. Бу бик сөендерә. Һәм без, укытучылар, ел тәмамланганнан соң да безнең һөнәргә һәрвакыт шундый игътибар һәм ихтирам булуын телибез», – диде ул.

Алинә әйтүенчә, җәмгыять җаваплылыкны укытучы җилкәсенә сала. Еш кына укытучы әти-әни өйрәтмәгәнне өйрәтергә, әти-әни бирмәгән тәрбияне бирергә, гаиләдә бала күңеленә сеңдерелмәгән кыйммәтләрне аңлатырга, ә кайвакыт әти-әни хатасын төзәтергә дә мәҗбүр.

Сәрия МИФТАХОВА

ТИМӘСЕН ТИК… ҺӨҖҮМЕ

Яшәргә өйрәнәбез

Киберһөҗүм, хакерлар, мәгълүмат урлау, онлайн мошенниклык… Кызганыч, бу сүзләр хәзер беребез өчен дә ят түгел. Белгечләр, тормышыбыз цифрлашкан саен, алар белән тагын да «туганлашу» куркынычы турында кисәтә.

Кайбер статистика мәгълүматлары бөтенләй дә куркуга сала. Дөньяда киберһөҗүмнәр ясаганда кулланыла торган ботнет компьютер челтәрләренең саны ике ел эчендә җиде мәртәбә (!) арткан. Бу турыда РИА «Новости» яза.

2021 елда мондый ботнетлар саны 70 меңгә якын булса, хәзерге вакытта дөнья буенча алар 500 мең җайланманы тәшкил итә. Өстәвенә аларның күпчелеге виртуаль машиналар базасында эшли, ә бу исә элеккедән дә көчлерәк DDoS-һөҗүмнәр ясарга мөмкинлек бирә икән. «EdgeЦентр» үзәге генераль директоры Михаил Шурыгин аңлатуынча, мондый ботлар катгый закон чаралары һәм тиешле җәзалар булмау аркасында арта. «Мондый тенденция киберкуркынычсызлык мәсьәләсендә шактый җитди проблемаларга китерергә мөмкин», – ди белгеч.

Тагын шуңа игътибар итәргә кирәк: мондый зарарлы ботлар DDoS-һөҗүмнәр ясаганда гына кулланылмый. Әлеге технологияләр финанс өлкәсендәге мәгълүматларны урларга, мошенникларга кешеләрне алдарга, теге яисә бу финанс операциясен автомат рәвештә башкарырга мөмкинлек бирә.

Әлеге язма белән берәүне дә куркытырга җыенмыйбыз, билгеле. Ә бары тик мәгълүмат куркынычсызлыгының ни дәрәҗәдә мөһим булуын искәртергә телибез. Саклану кагыйдәләре турында тәүге тапкыр сөйләмибез һәм язмыйбыз инде. Шулай да, хәтерне яңарту зыян итмәс.

Ничек сакланырга?

– Таныш булмаган кешеләр белән телефоннан сөйләшкәндә, «әйе» сүзен әйтергә ашыкмагыз. Бу сүз сезнең теге яисә бу гамәлгә ризалык белдерү булып кулланылырга мөмкин.

– Нинди дә булса оешма исеменнән шалтыратсалар, шул оешманың номерын эзләп табарга, шуның буенча шалтыратырга һәм әлеге номерның чыннан да бу компаниянеке икәнен тикшерергә кирәк.

– Компьютер браузерында шәхси мәгълүматны сакламаска (банк картасы номерын, парольләрне).

– Сайтларның адресына игътибар белән карарга кирәк. Кайчагында кырыгалдарлар сайтларны ялган пәрдәсе белән каплый, ягъни чын сайтка бик охшаш итеп ясый, ә эчлегенә төрле «тозаклар» кора.

– Дус-иш, туган-тумача, таныш-белешләрдән шикле хатлар килсә, уйга калыгыз, шундук ышанмагыз. – Интернет аша нидер сатып алганда, ниндидер хезмәт өчен акча күчергәндә, бу сайтны яхшылап өйрәнү мөһим. Шулай ук башка кулланучыларның кайтавазларын уку да зыян итмәс. «Предоплата», өстәмә түләү соралган очракта да, җиде кат уйларга киңәш ителә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН

Ботнет ул – киберһөҗүмнәр өчен кулланыла торган зарарланган компьютер челтәрләре. Киберһөҗүм яки хакер һөҗүме – теге яисә бу компаниянең мәгълүмат системасына зарар салу, сайтлар һәм кушымталарга, шәхси аккаунтлар һәм җайланмаларга үтеп керү, зыян китерү.

Рәсми хәбәр

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының кадастр бәясен билгеләү турында хисап проектын урнаштыру хакында, шулай ук хисап проектына карата искәртүләрне тапшыру тәртибе һәм срогы хакында хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы түбәндәгеләрне хәбәр итә.

«Дәүләт кадастр бәяләве турында» 2016 елның 3 июлендәге № 237-ФЗ Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү турында» 21.02.2022 ел, № 540-р Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгы нигезендә, хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларын дәүләт кадастр бәяләве үткәрелә.

Капиталь төзелеш объектларының кадастр бәясен билгеләү йомгаклары буенча, «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – ГБУ «ЦГКО») электрон документ рәвешендә башлангыч хисап документларын (алга таба – Хисап проекты) тутырган.

Хисап проектындагы мәгълүматлар һәм материаллар, дәүләт кадастр бәяләве мәгълүматлары фондын алып бару тәртибендә күздә тотылган күләмдә, 2023 елның 3 октябрендә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтындагы дәүләт кадастр бәяләве мәгълүматлары фондына утыз көнгә урнаштырылган.

Хисап проекты, кушымталарын да кертеп, тулы күләмендә ГБУ «ЦГКО»-ның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтының (http://cgko.tatarstan.ru) «Эшчәнлек» бүлегенә «Хисап проекты» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Хисап проектына карата искәртүләр 2023 елның 1 ноябренә кадәр кызыксынулы теләсә кайсы затлар тарафыннан ГБУ «ЦГКО»га, шәхсән, почта аша яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, электрон почта аша электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Моннан тыш Хисап проектына искәртүләр «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең (алга таба – ГБУ «МФЦ») теләсә кайсы филиалына тапшырылырга мөмкин.

Хисап проектына искәртүләрне тапшыру көне булып аны ГБУ «ЦГКО»-га яки ГБУ «МФЦ»га тапшыру көне, хат тапшыру турында уведомлениенең почта штемпеле оттискында күрсәтелгән көн (почта элемтәсе аша җибәргән очракта) яисә аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша тапшыру көне санала.

Хисап проектына искәртү, асылын бәян итү белән беррәттән, түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булганда), юридик затның тулы атамасы, Хисап проектына карата искәртү тапшырган затның элемтәгә керү өчен телефон номеры, электрон почтасы (булганда) адресы;

2) кадастр бәясен билгеләүгә карата Хисап проектына искәртү бирелә торган күчемсез милек объектының кадастр номеры, әгәр искәртү конкрет күчемсез милек объектына караган булса;

3) Хисап проектының искәртүләр бирелә торган битләре (бүлекләре) номерларын күрсәтү (кирәк булганда).

Искәртүләргә кадастр бәясен билгеләгәндә хаталар җибәрелүен раслаучы документлар, шулай ук күчемсез милек объектының характеристикалары турында декларация кушып бирелергә мөмкин.

Күчемсез милек объектларының характеристикалары турында декларация формасы һәм аны карап тикшерү тәртибе «Күчемсез милек объекты характеристикалары турында декларацияне, шул исәптән аның формаларын карап тикшерү тәртибен раслау турында» 04.06.2019 ел, № 318 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган.

Хисап проектына карата искәртүләр кабул ителә:

1) түбәндәге адрес буенча урнашкан: 420021, Казан ш., Париж Коммунасы ур., 8 й. (ишеге – бина почмагында, «БТИ» АҖ документлар кабул итү зонасы) ГБУ «ЦГКО»да;

2) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» ГБУ филиалларында (филиаллар исемлеге ГБУ «МФЦ» рәсми сайтында «Бүлекләр» бүлекчәсендә урнашкан (https://mfc16.tatarstan.ru/filials-map).

3) ГБУ «ЦГКО»ның электрон почтасы (Gbu.Cgko@tatar.ru) аша электрон документ рәвешендә (шәхсән имза белән документның сканер күчермәсе).

Тәфсиллерәк мәгълүмат, шул исәптән күчемсез милек объектлары характеристикалары турында декларация формасы һәм аны карап тикшерү тәртибе ГБУ «ЦГКО» сайтына (http://cgko.tatarstan.ru) урнаштырылган.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ТАУШАЛГАН БАКШАНДЫ

Борчылу

Без бу юлы кышын беркем дә яшәми торган авылны урап кайтырга булдык әле. Саба районының Бакшанды авылына өлкәннәр бары җәй көне генә яшәргә кайта. Техника булмаса, инешеннән чыга торган түгел. Ни өчен дигәндә, күпере юк. Сагыну хисе биләгәндә, андый каршылыкларга гына карамыйсың икән ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Минсара әби белән Нурфия апа яшьлекләрен искә төшерде.

Сары көзнең кояшлы матур көнендә барып кердек без Бакшандыга. Кеше яшәми торган авылда рөхсәтсез йөрү бераз читенрәк, әлбәттә. Ничектер, өйгә ишек шакымыйча кергән кебек. Без бер, берничә кеше генә яшәгән авылларның үткәне, бүгенгесе турында еш язып торабыз. Анда сөйләргә шаһитлар бар әле. Ә «телсез» авылда безгә беркем булыша алмаячак бит. Журналист буларак җим табылырмы? Буш урамнарда йөрүдән мәгънә булырмы? Шулай шикләнеп торсак та, тәки үзебезнекен иттек. Авылның бүгенгесен барып күрәсебез килде.

Җимерелмәгән дә, бетеп тә җитмәгән әле бу авыл. Әйтерсең кешеләр каядыр вакытлыча чыгып кына киткән. Дөрес, йортлар элеккеге кадәр юк инде. Заманасында 66лап йорты булган. Аларның урыны буш. Ә болай 7 йорт бар. Җәен дүртесендә тормыш кайный. Чү, кайдадыр бик дәртле җыр яңгырый. Димәк, кемдер кунакка кайткан яки җәй кайтканнан китеп өлгермәгән. Менә шушы җыр тавышына киттек урам буйлап үргә күтәрелеп. Иң беренче йортның капка төбендә тавыклар үлән чукый. Димәк, аның да ишегенә йозак эленмәгәндер.

Урам уртасында чишмә ага. Авыл халкы карап тота икән. Шул тирәдәрәк ике агач арасына атынчык ясап куйганнар. Ул, җил искәндә, ялгыз гына тирбәлеп куя. Без килгәндә, авылда өч йортта кешеләр бар иде. Минсара әби белән күршесе Нурфия ханымны чакырдык та, шул ялгыз атынчыкка утыртып, яшьлекләрен искә төшерттек. Көянтә-чиләк күтәртеп, чишмәгә дә алып бардык үзләрен. Сөйләгез әле, апалар, ни өчен авыл шушы хәлгә калган?

– Мин гомер буе фермада эшләдем. Пенсиягә чыкканчы мал асрадым. Ике улым бар. Кышка Казанга үзләре белән алып китәләр. Җәен атна саен кайталар. Унбер ел шулай яшим инде. Бер дә китәсе килми. Авылда бик рәхәт. Кышын юл булмагач, мәҗбүри генә барам, – ди 81 яшьлек Минсара Асатова.

Сүзгә Нурфия апа кушылып: «Авылда бөтен нәрсә дә бар иде, хәзер юк инде, юк, юк, ю-у-у-к… – диде. – Авылдашлар Арча, Кукмара якларына, Шәмәрдән бистәсенә күченеп китте. Картлар – бакыйлыкка… Шулай әкренләп таркалды инде Бакшанды. Авылга газ, су кертелгән. Юллар гына юк. Ярый әле үзебез басма салдык».

Нурфия ханым белән Арслангали абый ике кыз үстергән. Тиздән Түбән Камага шулар янына китәргә җыеналар. Кызлары хәл белешергә кайткан. Шашлык пешереп, бәйрәм итүләре иде. Музыка шушы йортта яңгырый икән. Картлар кулына калган авылда мондый көйләр сирәк ишетелә торгандыр хәзер.

Бетмәсен иде инде авыллар. Без аңа бик борчылабыз. Нигезне бер дә бетерәсе килми. Менә бу йортка кайтмыйлар инде. Сагындыра, бик сагындыра туган авыл. Түбән Камага киткәч, төшләргә дә кереп йөдәтә. Нурфия апа шулай ди.

Тавыклар үлән чемченеп йөргән йортка Флера апа ире Равил абый белән кайтып торгалый икән. «Капка төбенә чыгармый идек әле тавыкларны, чыгып киткәннәр бит», – диде Флера апа, уңайсызланып.

– Авыл беткәнгә йөрәгегез авыртадыр инде? – дип сорадык аннан.

– Авырта инде, балакай, барыбызныкы да. Бөтен нәрсә бетте бит… Әниләр сөйләве буенча, авылда 66 йорт булган. Әллә күбрәк, әллә азрак? Алар да белеп бетермидер инде аны. Авылның тарихын бик беләсебез килә. Тик ничәнче елда оешканын беркем дә әйтә алмый. Кибет, клуб, мәктәп бар, ферма гөрләп тора иде. Барысы да таркалып бетте. Мин Бакшандыдан 1967 елда чыгып киткән идем. Әни янына кайтып-китеп йөрдем. Хәзер җәен яшибез, – ди Флера Газизова.

Аның әйтүенчә, авыл бетүнең беренче сәбәбе – юл булмау. Юл булмагач, эш юк. Кышын чаңгы белән кереп, газ-суга күз колак булып китәләр икән. Юл булмагач, үзләре дә кышка кала алмый. «Авылга ашыгыч ярдәм дә керә алмый», – ди ул. Биек, карт агачлар өчен борчыла әле Флера апа. Җил-давыл чыкканда, агачлар чыбыкка авып, ут-күз чыгуы да бар. Кешесе аз булса да, тормыш бара бит әле. Шуларны кисәргә кирәк. Апабыз шулай ди.

– Безнең авыл халкы гомергә бердәм булды. Коръән ашы үткәрсәк тә, бар кешене чакырдык. Берәүне дә калдырмадык. Хәзер дә күршеләр белән аралашып торабыз. Берәү кайта алмаганда, икенчебезнең бакчасына суын сибеп торабыз. Менә шулай яшәп ятабыз, – ди Флера апа.

Сәрия МИФТАХОВА

Авыл җаны

Оптимизм

Авыл турында, авыл кешеләренең уйлары, фикерләре турында яза башлагач, бер нәрсәгә игътибар иттем: чынбарлык хакында оптимистик рухта сөйләүчеләр аз икән. Сәбәпләре аңлашыла, әлбәттә. Ләкин бит шунысы да бар: зарланып тормыш бармый, кайда да алгарыш – оптимистлар кулында, уңай үзгәрешләрне дә «булдырам» дип тотынучылар ясый.

«Без булдырабыз!» пафослы лозунг кына түгел, эчке шигарь икән, күп нәрсәгә ирешә кеше.

– Авылда оптимистларны фермерлар арасыннан эзлә син, – диде Мансур абый. Мин, гадәтемчә, килешмим бит инде. Адым саен киртә белән очраша кебек тоела алар миңа: бәяләр түбән, техника кыйммәт, кануннар буталчык…

Мансур абый да, гадәтенчә, мине үз мантыйгы белән шаккатыра. «Әгәр бертуктамый законнар, система, каршылыклар дип зарланалар икән, димәк, болар – булдыксызлар, – ди. – Белеп эшләсә, теләп эшләсә, бөтен көчләр булыша ул кешегә, андыйларны күп беләм мин. Үзе фермер булган, авылның дини тормышын алып барган хәзрәтне дә беләм».

– Хәзерге җир хуҗасы «отруб»лар булып яшәргә тели, – ди Мансур абый.

– Хуторлар кебек, аерым хуҗалык булып, авылдан читтә, димәкчеме әллә сез? – дим. Юк икән. Авыл эчендә, җайга салынган инфраструктураны файдаланып, ләкин мөстәкыйль булып, үзләренә эшләп яшәргә теләүчеләрне әйтә әңгәмәдәшем.

– Авыл кешеләренең бер ишләре аларны яратмый инде, көнләшәләр. Гомер бакый шулай булган. НЭП заманын гына исеңә төшер. Бераз ирек бирү белән, җирне, хезмәтне яраткан булдыклылар берничә елда аякка баскан. Ә җыен ялкау, хәерчеләр аларга батрак булып ялланган яки, «ялчылар тоталар» дип әләкләп, соңрак кулак дип сөрдерүгә ирешкән. Көчле хуҗалардан курыккан хакимият янә хөрәсән әтрәк-әләм ихтыярын алга куйган.

Мансур абый тарихи параллельләр китерергә ярата. Безнең бөтен бәлабез наданлыктан дип саный ул. Бу урында мин дә килешәм аның белән.

– Менә Ватан, ил, дәүләт, хакимият диләр, әйеме? Күпләр аларны бер үк итеп күрә. Фермерлар өчен Ватан ул – үзләренең туган җирләре, эшкәрткән басу-кырлары, якыннары, туганнары… Дәүләтне ятратканга түгел, менә шуларны яратканга көчләрен җәлләмичә тырыша алар. Хәзерге вакытта тормышны алга этәрүче көч шул авылда. Система белән дә, көнчел авылдашлар белән дә, табигать белән дә тарткалашалар. Үзләренең көчләренә ышанганга көчле дә, оптимист та алар.

Мансур абый белән бәхәссез генә килешеп (чөнки фермерлар белән ул күбрәк аралаша, димәк, белә), һәм саубуллашып, телефонымны куюга, күршеләремә кереп китәм. Анда безнең авылның иң җор, иң шаян кешеләренең берсе Фәрит абый яши. Әле кичә генә авыл мәзәкләрен сөйләп чыгып киткән иде. Аңа да соравымны бирәм. Оптимист, әлбәттә, ди ул. «Елап яшәргә ыштули?!»

– Миңа да гел: «Җилкәңне турайт, боегып утырма, үзеңне җәлләп утырсаң, кәкрәергә дә озак түгел», – дип кабатлап тора ул, – дип сүзгә кушыла җәмәгате Нәзирә апа. Яман чир белән көрәшкән вакыты аның.

Аз-маз сәясәт, аз-маз авыл хәлләре турында сөйләшеп утырсак та (уйлап карасаң, берсе дә әллә ни куандырырлык түгел), күршеләремнән күтәренке кәеф белән чыгып киттем мин. «Ирония судьбы» фильмының авыл варианты бездә булган икән. Фәрит абый белән. Яшь чакта, яхшы ук салмыш килеш кайтканда, өйләрне буташтырып, күршеләренә кереп, чәйләр эчеп, йокларга ята ул. Күрше Рафик абый сүзләреннән белә бу хәлләрне. Кызлары клубтан кайтты, дип уйлыйлар ишек ачылгач. Аннары шалтыр-шолтыр килеп чәй эчкән бу. Аннары тавыш тына, йокларга ятты, дип уйлыйлар. Үзләре зал ягында телевизор карап ята. Бераздан Рафик абый арткы өйгә чыкса, идәндә бер ир-ат ята. Танып ала инде, җилтерәтеп уята:

– Нишлисең безнең өйдә? – ди.

– Ә син бездә нишлисең? – ди исерек күршесе. – Бу – безнең өй. Әнә безнең шкаф, әнә безнең көзге!

Кыскасы, ике өйнең дә эчке төзелеше бер үк булып чыга. Бу хәлне соңрак көлке итеп сөйли башлыйлар.

– Кайткач, тагын кер, кызык-мызыкларны әзерләп куярмын, – дип озатып калды мине Фәрит абый. Тавышы элеккеге кебек көр булмаса да, йөзе һәрчак көләч аның. Ә тавыш булмауның сәбәбе – муенында һаман да көпшә тора. Берничә ел элек әшәке чир аңа да ябышкан иде, хәзер чигенгән, ди инде.

Сүз башым бит – Шүрәле, дигәндәй… Бүгенге дөнья, вазгыять турында оптимизм белән сөйләүчеләр аз булса да, оптимистлар шактый бугай безнең арада.

Лилия ФӘТТАХОВА

Яшәргә өйрәнәбез

МОНДЫЙ ХӘЛНЕ КҮРГӘН ЮК ИДЕ

Бу сүзләрне Дәрвишләр бистәсендәге 65 нче балалар бакчасында моңа кадәр тын гына эшләп яткан, бер ел элек яңа мөдир килгәч, шактый гына үзгәрешләр кичергән тәрбиячеләр әйтә.

Ялгышмаганнар

Яңа мөдир дигәнебез – Гөлназ Сафиуллина. Безнең өчен бик яңа да түгел әле ул. Моннан берничә ел элек балалар бакчаларында татар телен өйрәтү, гореф-гадәтләрне саклау эшләре белән танышып йөргәндә, 415 нче балалар бакчасына да барып чыккан идек. Гөлназ Минтаһированың шунда өлкән тәрбияче булып эшләгән чагы. Үзенчәлекле эш-гамәлләре белән шаккатырган иде ул безне. Остаз итеп, бөек мәгърифәтчебез Каюм ага Насыйрины алган да, балаларны гына түгел, ата-аналарны да бергә туплап, бик үтемле тәрбия эшләре үткәреп ята иде. Балалар үзләрен «Каюм бабай оныклары» дип атыйлар, татарча сөйләшәләр, бииләр-җырлыйлар, бабаларының канатлы сүзләрен, гыйбарәләрен яттан белеп, шул кагыйдәләрне күздә тотып яшиләр, ашыйлар, укыйлар, уйныйлар иде бу бакчада.

Моннан бер ел тирәсе элек, сентябрь аенда Гөлназ Сафиуллинаны Казан мәгариф идарәсе боерыгы белән 65 нче бакчага мөдир итеп күчергәннәр. Әмма бер шарт белән: тиз арада, бернинди каршылыксыз-нисез катнаш бакча төзергә һәм татар төркемнәрендә телне, гореф-гадәтләрне саклау буенча эш җәелдерергә. Тәҗрибәсе мулдан, булдырыр дигәннәрдер инде. Һәм ялгышмаганнар.

Нидән башларга?

– Милләтне үстерү буенча хәйран гына эшләр эшләдек, – ди Гөлназ Минтаһирова, эш-гамәлләре турында сорашкач. – Хәзер бакчадагы 12 төркемнең алтысы татар телле. Нидән башларга дигәндә, мин, кадрлардан, дип җавап бирер идем. Шунысын да әйтеп куйыйм: үзләре теләп китүчеләрне санамаганда, эштән җибәрүләр булмады, балалар да шундый составта калды. Барысы белән дә уртак тел табарга тырыштык. Элеккеге хезмәттәшләрем дә хәерхаһлы булдылар.

Беренче булып, 415 нче бакчада бергә эшләгән коллегасы Раушания Шәйхелисламова ярдәмгә килә. Өлкән тәрбияче булып урнаша. Шундук балалар, ата-аналар белән сөйләшүләр башлый. Кем татар телен яхшы белә, кем бөтенләй сөйләшә белми, кемнең өйрәнергә теләге бар, кемнеке юк – барысын да җентекләп белешә. Сораштыру үткәрәләр, анкеталар тутыралар, беркемнең дә теләгенә каршы килмиләр. 415 нче бакчаның элеккеге мөдире Рузалия Кадыйрова да, бу хәлләрне күреп, өйдә тик кенә утыра алмый. Инде ялга киттем дигән җиреннән чыга да ярдәм кулын суза. Гадәтләнгән эш бит инде. Бөтен нәрсә таныш. «Рузалия Әхәтовна – минем остазым. Күп нәрсәгә өйрәтте. Бүген дә ярдәменнән ташламый», – ди аның хакында шәкерте.

Дөрес, электән эшләүчеләр арасында башта аптырабрак калучылар да булган. Берән-сәрән киткәләгәннәр дә. Әмма күбесе эшнең җаена бик тиз төшенгән. Коллективның болай бердәм эшли башлавы күңелгә рәхәтлек өстәгән, төрле шөгыльләр табарга ярдәм иткән. «Бакчабыз яшәреп китте», – диләр кайберләре, әле бүген дә гаҗәпләнеп.

Ниләр булып ята?

Әллә ни баш китәрлек әйберләр дә юк кебек үзе. Татар телендә тәрбия бирә башлыйлар. Планнар татарча төзелә. Республика, район күләмендә татар телендә үткәрелгән бәйгеләрдә катнашалар. Арада төрлесе бар: миллиләре дә, инновацион юнәлештәгеләре дә. Юнәлеш дигәннән, татар телен өйрәнү дә өч тармак буенча алып барыла: тәрбиячеләр, әти-әниләр, балалар. Бакчада өйрәнеп кайтканнарын түкми-чәчми өлкәннәргә җиткерәләр икән дә, әти-әниләр бакчага килгәч, сөйләшеп күрсәтәләр, рәхмәтләрен әйтеп китәләр икән.

Ә яңа мөдир: «Тәҗрибә туплавымны дәвам иттерәм», – ди. Дөресрәге, күптән башкаларга өләшә инде ул аны. Үзе эшләп киткән бакчаны да онытмый. Бергәләп төрле чаралар үткәрергә дә вакыт табалар. Татар тәрбиячеләре өчен Совет районында 1995 елдан бирле эшләп килгән «Мирас» семинарын да соңгы тапкыр бергәләп оештырганнар. Балалар бакчалары өчен татар телендә эш дәфтәрләре әзерләгәннәр. Татарстанда гына түгел, чит өлкәләрдән дә заказ бирәләр икән. Алар арасында «Уйный-уйный өйрәнәм», «Ярый-ярамый», «Мавыктыргыч математика» дигәннәре бар. «Мирас» семинары өчен китапчыкларны яңадан бастырып чыгарганнар.

Телне яхшы белгәч, «Сәйяр» дип аталган Республика балалар-яшүсмерләр театрлары фестивалендә катнашу да берни тормый хәзер аларга. Татар телендә «Ачык авыз» дигән спектакль әзерләп яталар. Авторы да үзләренеке – Эльвира апалары. Автор дигәннән: «Тәрбиячеләрнең яңа сәләтләре ачылып кына тора. Язучылык эшенә керешеп баралар: шигырь дә иҗат итәләр, пьеса да язалар», – ди мөдир, уенын-чынын бергә кушып. «Бәйрәмнәрдә татарча шигырьләр сөйли башлагач, бәйгеләрдә катнашкач, балалар бигрәк тә кызыксынып китә. Телне белмәгәннәренең дә тизрәк өйрәнәсе килә», – ди Раушания апалары. «Җәлил укулары», «Татар малае» бәйгеләрендә җиңү яулаулары юктан гына түгел бит инде.

Әти-әниләр дә бик активлашып киткән. Берәр нәрсә эшли башласалар, булышырга кирәкмиме дип, хәзер килеп җитәләр, ди. Ә эшлисе эшләр күп әле. Балаларга төрле милләт вәкилләре киемнәре тегәләр. Ансамбльләр чыгыш ясаганда, йөз кызармаслык булсын. Музейны төзеп бетереп киләләр.

«Авылларга кайткач, экспонатларны үзебез җыеп килдек», – ди Эльвира Вәзиловна. Ни генә юк монда! Җилпуч, кер бәләге, икмәк салу өчен кәрзин, тимер үтүк… Шунысын да әйтик: музейның бер үзенчәлеге бар. Балалар, нәрсә икән бу дип, аптырашып тормасын өчен, элеккегесе янына хәзергесен дә куясы. Мәсәлән, борынгы үтүк янына – яңасын, сырлы такта янына – кер машинасын. Тиздән Идел буе халыклары мәйданчыгы да «аякка басачак». Фанердан зур сыннар кисеп, бер рәткә тезеп куячаклар аларны. Шулай итеп, Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан да зур эшләр эшләнә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА



БЕЗ БЕЛ(МӘ)ГӘН ҖӘЛИЛ

КАРИЕВ ТЕАТРЫНДА ТЕАТРАЛЬ ДӘРЕСЛӘР БАШЛАНДЫ

Премьера

Андре Тиммерманс, Әминә, Хәдичә Җәлиловалар, кечкенә Чулпан һәм Муса... Узган атна премьерасы – «Муса. Моабит» шигъри-музыкаль спектакленең геройлары бу. Кариев театры сәхнәсе – бер сәгатькә «Моабит» төрмәсенә, тамашачы Муса Җәлил тормышының шаһитларына әверелде.

Спектакльнең үзенә кучкәнче, аның форматы һәм максаты турында берничә сүз. Габдулла Кариев исемендәге яшь тамашачы театры, мәктәптә өйрәнелеп тә, шәхесләре тулысы белән ачылып бетми торган әдипләребезгә багышлап, театраль дәресләр циклын башлады. Алар укучылар өчен дә, студентлар һәм мөгаллимнәр өчен дә файдалы булырга тиеш. Алай гына да түгел, «Безне үзегезгә чакырырга була – «театраль дәресләр» белән без мәктәпләрдә дә, шәһәр паркларында да чыгыш ясарга әзер», – ди кариевлылар.

Кеше булып кала алу мөмкинме?..

Дәресләрнең беренчесе 6 октябрьдә узды. Соңгы арада исеме әледән-әле телгә алына торган каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган иде ул. Куючы режиссеры – Булат Гатауллин.

– Спектакльдә Муса Җәлилне герой гына түгел, ә гади кеше итеп ачарга телибез. Авыр тормышта ничек бирешмәскә дә ничек сынмаска? Без шуны күрсәтергә тырышабыз. Муса Җәлил белән бер чорда яшәгән кешеләр аның турында кызыклы хатирәләр әйтеп калдырган. Без, бүгенге заман кешеләре, аларны ничек итеп кабул итәбез? Минем өчен Җәлилнең хатыны Әминәнең истәлекләре дә бик кадерле. Ул Мусаның кыш көне майкадан гына чаңгыда шууын, гер күтәрүен искә ала. Җәлилнең әнә шундый гади кеше булуы кадерле дә, – ди Булат.

Шигъри-спектакльнең жанры турында Кариев театры директоры Луиза Шарова менә нәрсә ди:

– Без «Муса. Моабит»ның жанрын «кеше турында кыйсса» дип билгеләдек. Берәү дә каһарман булып тумый, сынау яки җаваплылык алдында калганда, каһарманга әверелә.

Спектакль – каһарманлык түгел, кешелеклелек турында. Монда җәберләүләр, сугыш-талаш, атыш, хәтта төрмә шартларына ишарә итүче гамәлләр дә күрсәтелми. Ләкин без шагыйрьнең нинди зур газап кичерүен шигырьләре аша аңлыйбыз. Җәлил турындагы истәлекләр исә шундый шартларда да кеше булып калырга мөмкин икәнен раслый.

Истәлекләр

Бу спектакльнең тагын бер үзенчәлеге һәм, мөгаен, иң уңышлы ягы – Муса Җәлилнең якыннарының «катнашуы». Аның «төрмә дусты», иҗатын безгә җиткерүдә өлеше бәһасез булган кеше – Андре Тиммерманс та бар монда, Мусаның сеңлесе Хәдичә дә. Җәлилнең кечкенә Чулпаны да йөгереп чыга. Уйларында булса да, кызы белән уйный, көлә ул. Хатыны Әминә Җәлилова да Мусасы турында сөйли.

> «Ул беркайчан да тормыштан зарланмады. Һәм аның өчен ниндидер аерым шартлар булырга тиеш дип тә санамады. Гел көләч йөзле, шаян, кирәк чакта сабыр һәм тыйнак иде. Кич утыруларны, дусларын яратты. Туры сүзле булды, иптәшләренә, уңышсыз килеп чыккан әсәрләре булса, үз фикерен әйтмичә калмый иде. Сугышка кадәр җиде елыбызны бик тату һәм рәхәт яшәдек. Кызыбыз Чулпан да икебезгә бик күп шатлык китерде. Ул чакта бәхетебезнең чиге булмас төсле тоела иде...»
>
> Әминә Җәлилова истәлекләреннән

Истәлекләр бик гади кебек. Ләкин без белгән әдипнең без белмәгән якларын ача. Ә композитор Миләүшә Хәйруллина иҗат иткән көйләр спектакльнең тәэсирен бермә-бер арттыра.

Бу фикер белән премьераны караган егет-кызлар да килеште. Яннарына килгәнче, үзара сөйләшкәннәрен тыңлап тордым.

– А ты знал про это?

– Нет, надо будет еще что-то про это почитать.

– Я половину не понимал даже, но знал о чем они говорят и поют.

Минем белән сөйләшкәндә, сүзләрен кыска тотты алар. Спектакльне ошатуларын, курсташларына да киңәш итәргә җыенуларын гына әйттеләр.

Әйткәнемчә, «Муса. Моабит» – дәрес рәвешендәге спектакльләрнең беренчесе генә. Чираттагысы исә Анна Ахматовага багышланачак. Монысын сер итеп кенә әйттеләр. Премьерасы ноябрь аена планлаштырылган.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Фикер

Халисә ШИРМӘН,
КФУ доценты, шагыйрә:
– Студентлар һәм, гомумән, яшьләр өчен бик яхшы спектакль бу. Билгеле, монда Муса Җәлилнең кем булуын, аның фаҗигасен алдан белеп килергә кирәк. Яшьләр театрына хас алымнар күп – ул яктан бик ошады. Тетрәндергеч, күңелгә тәэсир итәрлек урыннар җитәрлек. Фашистлар Германиясе музыкасының Җәлилнең тавышын басып китүе аеруча тетрәндергеч булды. Гомумән, спектакльнең музыкаль бизәлеше уңышлы дип санныйм. Ә менә ахырдан бер шигыре җитмәде. Дөресрәге, бер шигырьне яңгыратып, тамашачы күңеленә барып җитәрлек итеп укулары җитмәде.


Кариев театрының матбугат хезмәте

kazanfil.ru

«МЫРАУ БАТЫР» КАБАТ СӘХНӘДӘ

Тамаша

Ул көнне әти-әниләр кабат балачакларына кайтып килгәндәй булгандыр. Ник дигәндә, Казан филармониясе артистлары Нәкый Исәнбәтнең данлыклы «Мыраубай Батыр» әсәренә яңа сулыш өргән. «Чулпан» мәдәният сарае сәхнәсендә балалар өчен музыкаль спектакльнең премьерасы булды.

Күмәкләшеп җыелышып, телевизордан хәйләкәр песи турындагы «Мыраубатыр» телеспектаклен караган чакларын күпләр хәтерлидер. Ул чакта төп рольне Татарстанның халык артисты Илдар Хәйруллин башкарды. Хәзерге премьераның режиссеры да ул иде.

Илдар Хәйруллин, Татарстанның халык артисты:

– «Мырау Батыр» – Тукай әсәрләреннән бер дә ким түгел. Нәкый абый, песи маҗараларына төреп, бала күңеленә тел байлыгын да, тарихыбызны да, гореф-гадәтләрне дә биргән. Гаҗәеп әсәр бит ул! Кызганыч, бүген балалар татар китабын укымый... Мырау образын уйнаганда, миңа 36 яшь иде. Аннан соң күпме еллар узды, әмма хәзер дә юлда туктатып, мин сезнең Мыраубатырны карап үстем, дип әйтәләр. Бу – Исәнбәт тексты тәэсире бит инде.

Сюжет шул ук. Вакыйгалар Казан артындагы Бәрәзә авылында Ризван бай йортында башланып китә. Аның Мәрьям исемле кызы Мырау белән якын дуслар була. Әтисе Ризван гына бу дуслыкны өнәми: песине гел ачуланып, тычкан тотмыйсың, дип әрләп тора. Мырау исә баштарак тамашачы алдына, дөрестән дә, үтә ялкау кыяфәттә килеп баса. Ялкаулыгы шул дәрәҗәгә җитә ки, хәтта ул ауларга тиешле тычканнар үзенең үк өстеннән йөри башлый. Ризван бай түзми: ахыр чиктә Мырауны өйдән куып чыгара.

Иркә песи анда ниләр генә күрми. Әмма бер вакыйга Мырауның үзен дә, тормышка карашын да тамырдан үзгәртә! Урман явызлары – бүре, төлке, кабан һәм аю аның яраткан дусты Мәрьямне урлыйлар. Чарасызлыктан аптырап калган Мырау, кая барып, кемнән ярдәм сорарга да белми баш вата. Ахыр чиктә кызны үзе коткара. Спектакльнең иң кызык өлешләренең берсе шул: бу эштә Мырауга аның кан дошманнары булырга тиешле тычканнар да ярдәм итә! Бу мизгелдә залда дәррәү көлгән тавышлар ишетелде.

Гади генә вакыйга кебек. Әмма олысына да, кечесенә дә гыйбрәт алырлык мәгънә салынган. Мырау тамашачыны батырлыкка, һәр вакыйгадан өстен чыгарга өйрәтә, беркайчан да югалып калмаска, үз көчеңә ышанырга өнди.

Музыкаль театр форматындагы әлеге тамашада яңа алымнар табарга тырышулары сизелә. Балалар – иң ихлас, шул ук вакытта иң таләпчән тамашачы бит! Аларны шаккатыру өчен ай-һай тырышырга кирәк! Ә премьерага килгән сабыйлар спектакльне күз дә алмый карап утырды. Карарлык та бит! Якты, матур төсләр белән уралган сәхнәдә нәкъ әкиятләрдә сөйләнгән җәнлек-җанварлар кайнаша. Коры сүз сөйләү юк, бар да, хәтта гади аралашу да җыр-биюгә салынган. Шул рәвешле спектакльне кабул итү дә җиңелрәк.

Төп рольне яшь артист Рафаэль Якупов башкара. Мәрьям (Гөлназ Гафурова), Ризван бай (Айдар Габдинов), бүре (Рөстәм Асаев), төлке (Сөмбел Билалова), кабан (Ләйсән Мәхмүтова), куян (Ләйсән Закирова), баш күсе (Алмаз Хәсәнов), аю (Айзат Мардан), хикәяләүче (Фердинанд Фәтхи) рольләрендә күбебез яраткан артистларны күрергә мөмкин иде. Аларның осталыгы бәхәссез. Ә менә алар белән бергә балалар филармониясендә шөгыльләнгән, «Казан» бию ансамбленең балалар студиясендә йөргән сабыйларның да сәхнә тотуы, дөрестән дә, яңалык булды. Премьераның тагын бер үзенчәлеге бу. Мондый синтез булганда, кызыклы тамаша килеп чыга, билгеле.

Яшерен-батырын түгел, бүген татар балаларына тәкъдим итәрлек милли репертуар әллә ни зур түгел. «Мырау Батыр» музыкаль спектакле исә анда һичшиксез саллы урын алачак. Дәвамлы башлангыч булсын!

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САБЫЙЛАРЧА «ОСКАР»

«Милли мультфест»

Пластилин һәм кәгазь кирәк тә түгел, телефон да җитә! Замана балаларына мультфильм ясауның бер авырлыгы да юк. Өченче мәртәбә уза торган «Милли мультфест» балалар кинофестивале шуны раслый. Бу чараның асыл-әһәмияте нидә?

Нәрсә соң ул – «Милли мультфест»? Бик гади итеп аңлатсак, ул – балалар ясаган мультфильмнар һәм кыска метражлы фильмнар фестивале. Балалар өчен республика күләмендәге «Оскар». Әмма максат – аларны үзара ярыштыру түгел, балаларда татар теленә кызыксыну һәм мәхәббәт уяту. Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе гамәлгә куйган әлеге чара быел өченче мәртәбә узачак.

Кемнәр катнаша ала? Кинофестивальдә аерым коллективлар да, 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге авторлар да катнаша ала. Таләп бары шул гына. Авылда яшисеңме син, шәһәрдәме – анысы мөһим түгел. Фестивальнең башкарма директоры Миләүшә Айтуганова сүзләре белән әйтсәк, теләк һәм компьютер гына кирәк.

– «Милли мультфест»ны беренче тапкыр уздырганда, анимация дәресләре булган 48 мәктәп таптык. Ул чакта без әлеге мәктәпләрнең директорлары белән дә аралаштык. Һәм һәр районда, һәр авыл мәктәбендә анимация белән шөгыльләнү өчен мөмкинлек бар дигән нәтиҗәгә килдек. Бары теләк һәм компьютер гына кирәк. Анимация белән эшли торган программаларны табып алу авыр түгел, – диде ул балалар кинофестиваленә багышланган матбугат очрашуында.

Күп кенә фильмнарның (әйтик, «Вызов», «Сердце пармы», «Ибн Фадлан» һ.б.) компьютер графикасын ясаган «ДАЛИНА графикс» студиясенең директоры да, анимация ясау авыр, дип нәтиҗәгә чыгарырга ашыкмаска куша.

– Күп кенә ачык интернет-чыганаклар компьютер графикасы буенча бушлай дәресләр уздыра. Менә дигән мөмкинлек бит! Бүген мультфильм ясау өчен телефон да җитә хәтта. Иң мөһиме – бераз булса да белемне ныгытып, сыйфатлы итеп ясарга тырышу, – дип киңәш итте ул.

«Татармультфильм» оешмасының баш режиссеры Сергей Киатров исә балаларны анимация серләренә өйрәтүче укытучылар өчен бу фестивальнең яхшы мөмкинлек булуын әйтте.

– Аларның күпчелеге – энтузиастлар. Һәм алар эшләгән эшне еш кына күрмиләр дә. «Милли мультфест»та исә укытучылар да үзләрен күрсәтә ала, – диде ул.

Мультфильмнар, кыска метражлы фильмнар татар һәм республикада яшәүче милләт вәкилләренең туган телләрендә кабул ителә.

Нәтиҗәсе кайчан булыр? Әлеге фестивальдә катнашу өчен гаризаларны 15 октябрьгә кадәр җибәрергә мөмкин. Теләүчеләр күп булса, оештыручылар бу вакытны озайтырга да риза. Гомуми приз фонды – 1 млн сум. Иң шәп татарча мультфильм ясаучылар 100 мең сумга кадәр акчалата бүләк ота ала! Фестиваль җиңүчеләрен 26 ноябрьдә Казанның «Мир» кинотеатрында бүләкләячәкләр.

– Иң яхшы эшләрнең авторлары өчен «Байтик» лагеренда махсус смена оештырырга ниятлибез. Алар анда анимация ясап, төрле белгечләрнең остаханәләрендә катнаша алачак, – диде Миләүшә Айтуганова.

Узган ел фестивальдә 465 кеше катнашкан. Быелгы фестивальгә исә 400гә якын бала гариза җибәрергә өлгергән инде. Оештыручылар узган елгы санны куып тотып, узып китәргә өметләнә.

– Катнашучылар, яңа мультфильмнар мөмкин кадәр күбрәк булсын иде. Сан кайчан да булса сыйфатка әйләнәчәк. Безнең максат – әлеге юнәлешне үстерү, киләчәк өчен кадрлар әзерләү. Безнең балалар ясаган мультфильмнарны бөтен дөнья күрсен иде, – дип теләде фестивальнең башкарма директоры.

Сүз уңаеннан, узган елгы фестивальгә җибәрелгән иң яхшы анимацион фильмнарны «Шаян-ТВ» телеканалыннан һәм «ТатарКино»ның интернет чыганакларыннан карап була.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

vk.com

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Әйбәт булды, шома булды...

Шәһәр диварлары авыл хәрабәләреннән тезелә. Француз дипломаты, тарихи детективлар авторы Жан-Франсуа Паро шулай дигән.

Чынлап та, авыл булмаса, шәһәр нишләр иде икән?.. Буа төбәгендәге мин туган авыл «Маяк» күмәк хуҗалыгы составына керә иде. Алтмышынчы елларда яхшы ук нык хуҗалык булган, район күләмендә матди хәле буенча икенче урында торган. Хуҗалык җитәкчесе – Нурый Җамалиев. Ул тантаналарга филармония артистларын да чакырткан. Безнең авылдан өч чакрым ераклыкта «Алачкуак» дигән урман бар. Шул урманга кергән урында махсус сәхнә корылган һәм бик зур концертлар оештырылган. Моны инде ул заманнар өчен күрелмәгән хәл дисәм дә, ялгыш булмас.

Авылда чәчтарашханә ачканнары да хәтеремдә. Чәч кисүче – махсус укып кайткан Вилдан абый Шәмсиев. Чәч тә ала, сакал да кыра, гомумән, барысын да тиешле дәрәҗәдә эшли.

Мин үсмер чакта җәйләрен колхозда эшләгәндә, колхозның баш бухгалтеры Зәки абый Садыйков иде, безгә акчаны ул язды. Хәер, ул акчаны кулга тотып караганым булмады. «Акчаңны алдым, фәлән хәтле чыккан», – ди торган иде әткәй.

Авыл чәчтарашханәсенә Зәки абый да кергәли икән. Кереп утыра. Вилдан абый Зәки абыйның чәчен ала, сакалын кыра. Хушбуен да сибә. Бәлки, ярарга тырышыбрак та эшләгәндер әле. Ник дисәң дә, главбух бит! Вилдан абый эшен тәмамлауга, Зәки абый көзгегә карап: «Әйбәт булды, матур булды, шома булды... Рәхмәт!» – ди дә чыгып китә. Зәки абый гел шулай эшли торган була, түләү-түләмәү мәсьәләсендә сүз кузгатып тормый. Вилдан абый нәрсә эшли алсын, Зәки абый главбух бит!

Бу хәлне мин авылдашлардан ишеткәнем буенча гына яздым. Ничек булса да, күптән үткән хатирәләрне искә төшерү – күңелле нәрсә. Бу бит – бәләкәй генә булса да безнең тарих.

Илсур МОРТАЗА,
Татарстанның атказанган артисты

Югалды да, табылды да

Җырлый-җырлый бәрәңге чүпләгәндә, Нәфисәнең күзе ниндидер тимер кисәгенә төште. Ул аны саклык белән генә кулына алды. Бу – әнисенең бик күп еллар элек югалган тәңкәсе иде.

Нәфисәнең күз алдына бакый дөньяга күчкән әнисе килеп басты. Авыр сугыш елларын кичкән, сугыштан соң илне торгызуга үзеннән зур өлеш керткән кечкенә генә гәүдәле газиз әнкәсе.

Районнан шактый гына яшьләр белән Шпицбергенгә ягына юл алган, туган ягыннан бик еракта булган кап-кара күмер утравына аз булса да акча эшләргә дип килеп урнашкан аның яраткан әнисе.

Шушы утрауга барып, үзенең туган ягында, күрше авылда ук диярлек яшәүче егет белән танышып, кавышып та куялар. 1950 нче елларда туган якларына кайтып, шунда төпләнеп, бер кыз, ике малайга тормыш бүләк итеп, аларның сау-сәламәт булып үсүләрен сөенгән эти-әнисе бүген бу якты дөньяда юк инде.

Нәфисә югары сыйныфта укыган чагында, әниләре балаларны тезеп утыртты да сорау бирде.

– Балалар, шкафтагы менә бу бизәкле калай савыт эчендә ике көмеш тәңкә бар иде. Шуның берсе югалган. Кайсыгыз алды? – диде.

Балалар бер-берсенә сораулы караш ташлады. Ләкин «мин алган идем» дип әйтүче булмады.

– Балакайларым, мин ул тәңкәне күз карасыдай саклый идем, ул әбиегезнең әниемнән калган истәлек иде.

– Нәфисә кызым, мин аны сиңа бирергә дип саклый идем бит.

Эзләделәр, ләкин тәңкә табылмады. Еллар үтте. Эти-әниләре яшьли диярлек бакый дөньяга күчтеләр. Бервакыт барысы да җыелгач, тәңкә тарихын исләренә төшергәннәр иде. Шул чагында Нәфисәнең уртанчы энесе:

– Мин алган идем аны, бакчада уйнап йөргәндә югалттым, – диде.

Менә шулай, кырык еллап җир куенында яткан тәңкә – әнисенең Нәфисәгә истәлеккә дип бирергә уйлаган тәңкәсе бүген Нәфисә кулында. Йөгереп кереп:

– Әнием, мин ул тәңкәне таптым! Менә ул! – дип әйтәсе килде.

Әх, әйтәсе иде, әйтәсе… Барыбер әйтте ул аны. Әнисенең каберен чистартырга, догалар укырга баргач.

– Әнием, теге вакытта югалган тәңкә табылды. Ул хәзер үз иясенең кулында. Ә мин аны ядкарь итеп кызыма калдырачакмын, – диде.

Рафилә ФӘТТАХОВА.
Кукмара шәһәре

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сагындыра, төшкә керә авылым урамнары...

ГҮЗӘЛ ҖЫРЧЫ

Татар җыр сәнгате тарихында Зифа Басыйрова үзенә бер аерым зур урын алып тора. Тавыш тембрын, җырлау алымын һичбер җырчыныкы белән бутап булмый торган үзенчәлекле җырчы ул. Шөкер, олпат җырчыны бүген дә онытмыйлар. Әле күптән түгел генә яшәгән йортына мемориаль такта куелды. Бу минем дә хатирәләремне яңартты.

Бөек Ватан сугышы еллары һәм сугыштан соңгы чорда халкыбызның әчке кичерешләрен җырларында ачып биргән, тирән күңел моңы, дәртле җырлары аша бик күп кайгы-хәсрәт күргән халкыбызның күңелен юаткан, патриотик рухтагы җырлары белән сабырлыкка өндәп, яшәү дәрте уятырга омтылган һәм шушына ирешкән җырчы Зифа Басыйрованы мин башлыча язмалары аша беләм. Татарстан дәүләт радиосыннан җырлавын тыңлап үстем. Ә инде Казанга укырга килгәч, ике генә тапкыр булса да, үзен дә күреп калдым.

Беренче мәртәбә күрүем Казан урамында булды: ни күзем белән күрим, урамның икенче ягыннан Зифа апа атлый! Их, шул вакытта куып җитеп исәнләшәсем, эндәшәсем-сөйләшәсем калган икән – базмадым. Минем өчен ул – буй җитмәслек кеше, бик хөрмәт иткән, соклангач җырчым иде шул.

Үзеннән соң килгән җырчыларга да тәэсире зур булды. Профессиональ сәхнәдә дә, үзешчән җырчылар арасында да аңа охшатып җырларга тырышучылар күп иде. Күкрәктән агылып, ярып чыккан моңлы тавышы, җырның логик ритмын нечкә тоемлавы, җырларындагы дәрт, чатнап торган ачык дикциясе белән Зифа Басыйрова күпләр арасында аерылып тора. Арттырмый-киметми генә әздереп җырлаган борма-бизәкләре дә җырның мәгънәсен ачып бирүгә юнәлтелгән.

Зифа ханымны икенче мәртәбә Актерлар йортында күрдем. Ул анда зур концерт бирде. Аны залда утырып йотлыгып тыңлаучыларның берсе мин идем. Беренче һәм соңгы мәртәбә залдан тыңлавым булган икән бу гүзәл Җырчыны. Зифа ханымның лаеклы ялда чагы иде (әмма ул һаман халык арасында булды, сәхнә тотты), шушы концертыннан соң ул озакламый бакыйлыкка күчте.

Зифа Басыйрованың ул концерты әле дә күз алдымда, ә тавышы колагымда яңгырый. Микрофонсыз гына бер-бер артлы бик күп татар халык җырларын баянга кушылып җырлады ул. (Ул вакытларда әле сәхнәләрне микрофон – тавыш көчәйткечләр яулап алмаган иде.) Җырчының тавышы микрофонсыз да залны тутыра, үзе бик сөйкемле, килешле итеп киенгән. Никадәр җырласа да, халык һаман сорап җырлатты да җырлатты Зифа ханымны. Концертның бер өлешендә алар, танылган җырчы Динә Сираҗетдинова белән ике кодагый ролен кереп, спектакльдән өзек уйнадылар. Яраткан җырчыбыз Зифа Басыйрованың искиткеч актёрлык осталыгына ия булуын мин шунда күреп шаккаттым. Ул үз ролен шулкадәр ышандырырлык итеп башкарган иде ки, зал тулы халыкның рәхәтләнеп, тәгәрәп китеп көлгәне бүген дә күз алдымда.

Минем күңелемә шулай тоела: Хак Тәгалә тарафыннан Зифа Басыйровага зур миссия йөкләнгән. Ул халыкның үзеннән халыкчанлыкны чумырып алып, татар җыры һәм музыкасы әнҗесе булган мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләйманова мәктәбен үтеп, халыкчан җырлау сәнгатен кабул итеп алган да, зур җаваплылык хисе белән, әнҗе бөртекләрен учына җыйган хәлдә, аңарга бик сак карап, кадерләп, үз моңына төреп, үстереп, үзеннән соң килгән буыннарга түкми-чәчми әманәт итеп китереп тапшырган. Ә моңдый миссияне зур талант иясе булган, үз халкын, үз халкының моңын-гамен тирәнтен сөйгән, аңлаган Шәхес кенә үти ала. Зифа Басыйрова – чын халык җырчысы. Шулай булып тарихта калды, халкы күңелендә яши.

Зөһрә СӘХӘБИЕВА,
Татарстанның халык артисты

ГАИЛӘБЕЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Арча районы Урта Бирәзә авылында Фәйзрахмановлар урамы бар. Ул урамда авылның башлангыч мәктәбендә укытучы, мәктәп директоры булып эшләгән Бибинур һәм Фәтхрахман Фәйзрахмановлар гаиләсенең нигезе, алар яшәгән йорт урнашкан. Хәзерге көндә төп йорт – гаиләнең төпчеге Айдар Фәйзрахманов карамагында.

Фәйзрахмановларның балалары арасында да укытучылар бар: олы кызлары Флера – тарих фәннәре докторы, профессор. Олы уллары Марсель – гомере буе Арча педагогия көллиятендә хезмәт куйган мөгаллим. Минем – уртанчы кызның да уналты ел укытучылык стажым бар. Төпчекләре Айдар шулай ук Казанда институтта укыты, профессор дәрәҗәсенә ирешкән. Бүген гаиләбезнең иң кадерле истәлекләре белән бүлешергә булдым.

Бәхетле комган

Әтиемнең сугыштан кайту хәбәрен әниемә Арча базарында йөргәндә ирештерәләр. Комган алырга килгән була ул. Шулкадәр газапланып, әтиемнең исән-сау кайтуын көтеп яшәгән әнием, хәбәрне ишетүгә, сатып алган комганын күтәреп, шатлыгы турында барлык базар халкына хәбәр итә: «Бәхетле комган! Бәхетле комган! Фәтхрахманым кайта!!!» – дип кычкырып йөри…

Ул комганны хәтерлим әле мин. Кечкенә булсам да, су буена ком белән чистартырга алып төшә идем. Сап-сары, алтын сыман ялтырый иде ул комган чистарткач. Яньчелгән җирләре дә бар иде…

Гармун уйный алмас инде...

Безнең әтиебез сугыштан байтак вакыт госпитальләрдә дәваланганнан соң, яраланып кайта. 1945 елның октябрендә. Аны каршыларга әнием, ат юнәтеп, арбага әтиемнең гармунын салып, Арча станциясенә китә. Хәйран озак вакыт поезд килгәнне көтә ул. Ниһаять, әтием кайтып җитәргә тиешле поезд килеп туктый. Әнием, кулларына гармун тотып, әтиемнең гармунын сыздырып уйнап кайтасы мизгелләрне күз алдына китереп, вагон ишеге ачылганын көтеп басып тора. Ишек ачылып китүгә, әтием күренә. Ябыккан… Бинтка уралган уң кулын яулык сыман нәрсә белән күкрәгенә аскан… Әнием сискәнеп китә, әтием аңа уң кулы яралануын, әле сәламәтләнеп бетмәгәнен хәбәр итмәгән була… Борчыйсы килми. Әтиемнең гармунда уйнавын сагынган әниемнең башыннан: «Гармун уйный алмас инде», – дигән уй яшен тизлеге белән узып китә. «Үзе исән бит!!! Үзе!!!» – дип кычкыра ул шатлыгыннан, үз-үзенә җавап биргәндәй.

Бубик

Сугыштан исән кайтканнар бирешәмени?! Әтием дә, балтаны уң кулына бәйләп куеп, сул кулы белән булышып, яралы кулын утын ярырга өйрәтә… Эшләтә торгач, яралы кул тәмам сәламәтләнә. Мин үземне белә башлаганда, әтиемнең кулы яралы икәнне беребез дә искә дә алмый иде инде. Бармаклары да гармун телләрендә биеп кенә тора. Ә инде аның гармун уйнаганын тыңлау дөньяны оныттыра, күңелне сихри моңга күмә торган иде. Шулай бервакыт баскыч төбендә әтием гармун уйный (эш арасында андый мизгелләр дә була иде). Без, бала-чагалар, шатланып тыңлыйбыз. Безнең тирәдә этебез дә кайнаша. Хәйран зур гәүдәле ак этебез. Бобик исемле (ул исем каян килгәнен белмим, безгә ул татарга хас булмаган исем кебек тә тоелмый иде; без аны үзебезчә «Бубик» дип, «у» белән әйтеп чакыра идек). Этебез берзаман әтием янынарак килеп, аңа карап утыра башлады. Әтием, уйнавыннан туктап, Бубикның башыннан сыйпап куйды да үзәкләргә үтәрлек итеп моңлы көй уйнап җибәрде. Шулчакны Бубик, башын күккә сузып әтиемә кушылып акрын гына улый башлады. Әтием уйнап туктаганчы шулай улады ул. «Җырлады». Без, моңарчы мондый хәлне күрмәгән бала-чага, шып булдык. Бу хәлгә хәйран калдык.

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

Яшьлегем хатирәләре

КАДЕРЛЕЛӘРЕМ

Әни һәркайсыбызга бик тә газиз. Тик мин сүземне дәү әниядән башлыйм әле. Чөнки балалык, үсмер елларым дәү әниядә үтте диярлек. Какча гәүдәле, зәңгәр күзле чибәр дәү әнием минем! Китаплар укыштыргаласа да, артык гыйлем иясе дә, диндар да түгел иде. Пушкин няняьлары кебек әкиятләр дә сөйләмәде, җыр-бәетләр дә көйләмәде ул. Әмма үзенең яшәү рәвеше, кырыс назы белән безгә менә дигән сабак-тәрбия бирде.

Әни исә кырысрак булды. Ишле бала үстерү, гаилә белән алты-җиде тапкыр күченеп йөрүләр үз йогынтысын ясагандыр, мөгаен. Әниемнең яңа якларын мин соңрак – шактый еллар үткәч кенә ачтым. 1965 нче еллар. Безнең йорт Әмәт тавы итәгендә. Безнең – бер төркем студент яшьләрнең – әдәби мәйдан яуларга йөргән чагы. Тихогорская урамындагы (үзара шаярышып, без аны «Тихий гүр» дип тә йөртә идек) 5 нче йорт байтак яшь шагыйрьләр өчен, дулкынга кунып ял иткән акчарлак кебек кенә булса да, бер җыелу, сыену урыны булды ул елларда. Кемнәр генә булып китмәде бу йортта, нинди генә ялкынлы һәм хыялый сүзләр сөйләнмәде! Мин Әлмәткә эшкә киткәч, бу йортта тора-бара энекәшем Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет) яшьтәшләре белән җыела торган булып китте. Үзенә күрә шул чор яшь татар әдәбиятының рәсми булмаган бер штабы сыман иде бу йорт. Ә әлеге кырыс дигән әнием шул әдәби салонның «комендант»ы иде. Җыелган яшьләр янына әле чәй кертер, әле коймагын куяр, сирәгрәк булса да бәлешен дә чыгарыр...

Дәү әни һәм әни – сабыр, үзенчә горур, тырыш, гап-гади татар хатын-кызлары. Авыр хезмәт юлы үтеп, ишле балалар үстереп, аларны кеше иткән, тәрбияләгән әниләр, дәү әниләр – бездә миллионнар.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН,
халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге
Дәүләт бүләге иясе

«УФАЛЛА» АРБАСЫНДА БАЛАЧАККА КАЙТУ

Авылымның баш әйләндергеч саф һавасын, болыннарының хуш исле чәчәкләрен иснәп, ял көннәре җитсә, радиоалгычтан татарча концерт-спектакльләр тыңлап, татар моңнарын сеңдереп үскән бала мин. Әтием белән әнием дә эштән буш вакытларында тыңларга тырышалар иде концертларны. Габдулла Рәхимкулов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Гали Ильясов, Эмиль Җәләлетдинов, Флюра Сөләймановаларны бик тә ярата идек. Ул җырлардан өебезгә нур сибелеп, җанга рәхәт була иде. Җыр-моңга гашыйк булып үскән балалар без. Өч бала үстек. Олы абыем гармунда уйный иде, икенче абыем гитара кылларын тибрәтте, әнием матур итеп кубызда уйнады, мин аларга кушылып җырладым.

Габделфәт Сафинның җырларын бик яратып тыңлыйм. Мин – аның фанаты. Сәхнәдә үз-үзен тотышына, моңлы җырларына, көчле тавышына битараф булмаган татар баласымын. Җырларын күңел түрендә йөртәм.

Шуларның берсе – «Уфалла» арбасы» бигрәк тә якын. Ник дисеме? Чөнки нәкъ шул арбаны тартып үстем. Әнием, ике абыем да тартты. Җырны ишеткәч, балачагым күз алдыма килеп баса, күзне яшьләр каплый.

Нужаны күп күрдек. Мин туган елда өйдә туйганчы ашарга ипи дә булмаган. Әтием берничә эштә эшләгән, ул вакыттагы хезмәт хакы ташка үлчәрлек бит. Өч баланы ашатып, киендереп аякка бастыру өчен күп көч таләп ителгән. Әле бит аларны башкалардан ким итәсе дә килми. Өчебезгә югары белем алырга ярдәм итүче дә – әтиебез.

Ничек кенә авыр булса да, тормышта югалмадык, үз юлыбызны, үз урыныбызны таба алдык. Сынмадык, кеше булып калдык.

Әниебез арабыздан киткәч, шигырьләр яза башладым. «Хәзер тормыш җиңел, рәхәт», – дибез. Ләкин «чеметеп торган» вакыйгалар күбәя башлады. Вирус дигәне килеп керде. Элек яккан мунча, суган-сарымсакның файдасы тисә, хәзер, дәваланып та, адәм баласы кырыла.

Ә менә бу шигырьне язарга «Уфалла» арбасы» җыры этәргеч булды.

Чокырлы юлдан күп тарттык
«Уфалла»ның арбасын.
Күз яшьләренә коенып,
Маңгай тирләрен түгеп.

Уен уйнап үсмәдек без,
Урлап ашадык борчак.
Авыр эшләр эшли-эшли,
Үтеп китте балачак.

Язмышымнан зарланмыйм,
Сабыр гына атлыймын.
«Уфалла» арбасын тартып,
Нужа күргән бала мин.

Туган нигез ятим калган,
Әткәй-әнкәй күптән юк.
Балачакның нужасы да
Арбада калган кебек.

Хәзер зур шәһәрдә яшим,
Туган якны сагынып.
«Уфалла» арбасы гына
Тора үзәкне өзеп.

Зөлфия ИБРАҺИМОВА.
Бөгелмә

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юлларга әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

Авыл язмалары

Марат КӘБИРОВ

Сөенсеннәр әле...

Җирнең хуҗасы – кеше, дигән сүз аз гына шалтырап ишетелсә дә, дөреслектән мәхрүм түгел. Күп нәрсәләр кешегә бәйләнештә үзгәрә. Урман-елгалар да, аларда яшәүче тереклек тә. Хәзер тирә-якта моңарчы күрелмәгән җәнлек-җанварлар, кош-кортлар күренгәли башлады. Урманда аюлар да бар икән, кешеләрне ботарлап та ташлый икән, дип сөйлиләр. Берни дә әйтеп булмый. Бу заманда ышандырмый торган ялган юк…

Бездән ерак түгел генә ялгыз бер әби яши иде. Шул бакыйлыкка китеп барды да песие калды. Хәзер якын-тирәдәге кешеләргә керештереп йөри. Якты чырай күрсәткәч, безгә иләште. Хуҗабикәсе дә бик әйбәт кеше иде, урыны җәннәттә булсын, аннан калган мәхлукны үги итеп булмый бит.

Ямьсез генә песи ул. Кинәт күрсәң, куркып качарлык. Кыш көне килде беренче тапкыр. Арка үзәге кутырлап беткән, күз төбе сыдырылган, сирәкләнеп калган озын йоннары тырпайган… «Куып чыгарыргамы, кызганыргамы моны?» – дип икеләнеп торган арада, утын сараена кереп китте. Салкын иде көн. Куып чыгарырга җәлләдем, иске фуфайкага төреп, бер урынга менгезеп яткырдым моны. Бераз уйлап торгач, өшетә башлады. Тукта, бу да өшидер дип, аш җылытып чыгарып бирдем.

Шуннан иләшеп китте. Хәзер көн дә диярлек килеп йөри. Дөньяның иң ямьсез җанвары да беренче күргәндә генә шулай тоела. Күз өйрәнгәч, бөтен нәрсә дә матуррак булып тоела башлый. Баштарак мин: «Ярый, матур песиләрне матур кешеләр тәрбияләсен. Миңа синең ишесе дә җиткән», – дип уйлаган идем. Хәзер харап сөйкемле булып күренә. Килмичәрәк торса, юксына башлыйм.

Карт инде үзе. Баштарак мин аны ит белән сыйлый торган идем. Ә теге ашамый. «Ит тә ашамагач, яп-яланаяк, нәрсә көтәсең соң?!» – дип тиргим тегене. Тәмлерәк нәрсә сорыйдыр кебек тоела. Алай булмаган икән. Күзәтә торгач төшендем, тешләре үтми икән бахырның. Итне генә түгел, хәтта икмәк катысын да интегеп кенә ашый. Хәтта токмачны да…

Һәркемнең үз мөмкинлекләре бит инде. Һәр мөмкинлекнең – үз бәхете. Кемгәдер – алтын, кемгәдер – сәламәтлек, кемгәдер – бер кочак наз. Песиләрнең дә хәле безнеке шикеллерәк икән.

Дөнья тулы матурлык, байлык. Бер кеше яки төркем генә боларның барысын да кулланып, үзенеке итеп бетерә алмый. Алар кешегә канәгатьлек бирерлек дәрәҗәдә генә кирәк. Мәхәббәт, җенси бәйләнеш шикелле. Мәхәббәте күпме генә ташып торса да, көне-төне кочаклашып кына ятмый бит инде адәм баласы. Үзенә җитәрлеген ала да калганын калдырып тора. Артыгы аңа кирәкми дә, булдыра да алмый. Дөньяның байлыгы да, матурлыгы да шулай инде. Без аны аңлап кына җиткермибез. Безгә бөтен нәрсә дә үзебезне куандырырлык дәрәҗәдә генә кирәк. Артыкка китсә, бу – чир, патология. Маньяк булу сыман. Иң җай очракта да без ит ашарга тырышкан тешсез песи хәлендә калабыз: ашый да алмыйбыз, туймыйбыз да, көчне сарыф итәбез һәм тешне авырттырабыз.

Шулай уйлыйм теге песигә карап. Хәзер инде мин аңа йомшаграк ризык әзерләп бирәм. Ашап бетергәнче күз-колак булам. Чөнки тирә-юньдәге яшьрәк мәчеләр моны куып җибәрергә генә тора. Тешсез песи ул дәүләтсез милләт кебек бит инде, беркемгә берничек карыша алмый. Эте дә, бете дә өркетергә генә тора.

Кайчагында келәттән тычкан тотып алып чыга. Үзе ашамый инде, минем алга китереп сала. Мактануы да, эшен күрсәтүе дә түгелдер кебек. Шулай да кайчагында бу аның мине сыйларга тырышуыдыр сыман тоелып китә. Бәлки, чынлап та шулайдыр. Белми бит инде минем ул тычканга тешем үтмәгәнне. Бәлки, эченнән генә: «Шуны да ашамагач, яп-яланаяк, нәрсә көтәсең соң?!» – дип тирги дә торгандыр әле…

Кызык песи ул. Кешеләре сирәкләнгән авылның бер бизәге. Ихатада, минем компьютер алдында утырган чакта килсә, бер тавыш та чыгармый, «Мияу» дигәнне аңлатып авызын гына ача. Өнсез генә мияулый. Шуннан ялманып куя. Аңлашыла бит инде нәрсә сораганы.

Гомумән… Бер-береңне аңларга тырышып яшәсәң, хәтта песи белән дә күңелле. Аңлаша алмасаң, кеше булуның да дәрәҗәсе төшә. Кеше булуның кимәлен сакларга кирәк инде. Әле менә ашарына әзерләп йөрим. Үз-үземне дәртләндергән булам:

– Синең җирдә яшәвеңә хәтта песиләр дә сөенсен.

Песиләр генә сөенә микән инде…



ИГЕЗӘКЛӘР АВЫЛЫ

Сәвия Әхмәтҗанова белән Сәрия Фәттахова.

Ләйлә Шиһабиева

Алия, Альберт, Альфред Өметбаевлар.

Соклану

Бу авылда 25 пар игезәк туган. Аларның иң өлкәненә – 71, иң кечесенә ике яшь тә тулмаган әле. Апас районының Карамасар авылында яшәүчеләр, игезәк бәби алып кайту чишмә суына бәйле, диләр.

Авылларында өч чишмә бар икән. Кайсының көче зурдыр, әйтә алмыйлар. Ә игезәк бала үстерүчеләр туганлык җепләренең ныклыгы, бер-берләренә булган хисләре белән сокландыра.

Күптән түгел Карамасар мәдәният йорты хезмәткәрләре шушы авылдан чыккан игезәкләрне барлап, зур бәйрәм уздырган. Китапханәче Альбина Нигъмәтҗанова әйтүенчә, бәйрәмдә авылның үзенчәлеген күрсәтәселәре килгән.

– Карамасарлыларны берләштерәсе килде. Читтә яшәүче авылдашларыбызны җыеп очраштырдык. Игезәкләребезне барладык, – ди ул.

Асия – Сания

Альбинаның үзенең әнисе дә – игезәк сыңары. Асия белән Сания апаларга 71 яшь. Яшьлекләре бергә узса да, соңгы елларда игезәге белән күрешә алмыйча яшиләр.

– Безнең олы апабыз да бар иде. Аннан соң без туганбыз. Әти белән әни, мәктәпне тәмамлар алдыннан, сезне алга таба укыта алмыйбыз, дип әйтеп куйды. Сания белән заводка эшкә урнаштык. Озак та үтмәде, мин кияүгә чыктым. Ирем Яшел Үзән районының Күгәй авылы егете иде. Бераздан Сания дә бер егет белән танышты. Әби-бабасы Арчаныкы иде аның. Украинадан кунакка кайткан Шамил, Санияне ошатып, үзе белән алып китте. Алар шунда яшәп калды, – ди Асия апа. – Элегрәк күрешеп тора идек. Соңгы вакытта бары тик телефон аша сөйләшәбез. Алар Луганск шәһәрендә яши.

Асия апа игезәк сыңары белән ничек тә очрашып булыр дип өметләнә. Сания апа белән Шамил абый, йортларын калдырып, кайтып китәргә батырчылык итми икән.

– Игезәкләрнең сиземләве көчле аның. «Сания нихәл икән?» – дип кулыма телефон алсам, аның да шалтыраткан чагы була. Беребез – монда, икенчебез анда булса да, күңелебез белән бер-беребезне тоеп яшибез. Тизрәк күрешүләр насыйп булсын иде инде. Бик сагындым, – ди Асия апа.

Ринат – Булат

Әниләре Алзилә апа Сәмигуллова сөйләвенчә, аларның нәселләре дә игезәкләргә бай булган. Иренең энесе дә, үзенең әбисе дә игезәк сыңары була.

– Табиб, ике бала, дигәч, ышанмадык. Ул чакта улыбыз Илгизәр бар иде. 2002 елда Ринат белән Булатны алып кайттым. 2008 елда кызлы да булдык, – ди Алзилә. – Икесен бергә имезгән чаклар да булды. Бик авыр иде. Әле ярый каенанам булышты. Аңа рәхмәт. Малайларны ул үстерешеп. Алдына гел утыртып, халат итәге тузып бетәр иде.

Шөкер, егетләр икәү бергә хәрби бурычларын да үтәп кайткан. Элегрәк үзара тыныша алмасалар, сугышып та алсалар, армия үзгәрткән. Бер-берсенә бик якынайганнар.

– Аларны кеше аера алмый. Мин күзләреннән таныйм. Берсенеке зәңгәр, икенчесенеке күк, – ди әниләре. – Әле бер балам да гаилә кормаган. Улларым абыйлары белән Казанда яши. Икесе бергә МЧСка эшкә керделәр. Игезәк оныклар сөярмен әле дигән уем бар.

Сәвия – Сәрия

Алар икесе дә бер-бер артлы бер авылга кияүгә чыга. Карамасар кызлары Кайбыч районының Мөрәле авылы киленнәре булып куя.

– Безнең нәселдә элек тә игезәкләр булган. Сәрия белән бик рәхәт, дус, тату яшибез. Электән парлап киенергә яраттык. Әле дә гел бертөрле киемнәр сатып алабыз. Еллар узган саен, бер-беребезгә охшавыбыз арта бара. Үлчәмнәребез дә бер, – ди Сәвия.

1993 елның августында йөргән егете, әйдә, киногА, дип чакырып чыгара аны. Машинага кереп утырса, Сәрия дә, аның егете дә шунда була. Берни турында уйламыйча, Мөрәлегә барып җитәләр. 18 яше яңа тулып киткән кызны Фирдүс урлап алып кайта. Төнге унбер була ул чакта. Өйләренә килеп керсәләр, булачак каенанасы өстәл хәстәрләп куйган.

– Төнге беренче яртыда мулла чакырып никах укыттылар. Шөкер, гаилә коруыбызга – 30 ел. Начар яшәмәдек. Каенанам белән 23 ел бергә тордык. Ирем дә бик акыллы булды, – ди Сәвия.

1994 елның гыйнварында Сәрияне дә урлап алып кайталар. Булачак ире Илфат белән туйга баралар. Шуннан егет кызны үзләренә алып кайтып китә. Иртәгесен никах укыталар.

– Безне әле дә бер-беребез белән бутыйлар. Сәрия безгә килсә, «Сәвия, кая бардың?» – дип сорыйлар. Пардан да киенгәч, кеше танымый инде, – ди ул. – Әле ярый бер авылга кияүгә чыкканбыз. Бөтен тормыш бергә безнең. Аралашып яшибез. Зур эшләрне бергәләп башкарабыз. Мин ансыз, ул минсез тора алмый. Сәрия авырып китсә, шундук авырганын сизенәм. Ул да минем хәлемне шулай сизенеп тора. Мин күрше авылдагы картлар йортында эшлим, Сәрия мәктәптә идән юа, – ди Сәвия.

Альберт, Альфред, Алия

Фәридә һәм Рәшит Өметбаевлар өчләтә бәхетле. Улларына иптәш алып кайтабыз дип, алар берьюлы өч сабыйга гомер бүләк итә. Апас табиблары беренче УЗИда ике бала күрсә, икенчесендә, өчәү, дип кайтара.

– Ирем, үстерербез әле, диде. Миңа шул сүз җитә калды, – дип сөйли Фәридә апа. – Табиблар балаларны үземә таптырмады, Казанга җибәрделәр. Анда инде балаларны ярып алдылар. Малайларым бик елак булды. Ирем белән бергә карадык. Ул чакта ике улым бар иде. Олы улым Ринатка – 12, икенчесе Айратка 7 яшь иде. Мунчадан берәмберәм ташыганда, Ринат туганнарын карап торды. Үстерү җиңел булмады. Ничек тә тырыштык. Ул чакта керне дә кул белән юа идем. Игезәкләрне бакчага урнаштыргач, азрак ял күрдем.

Альберт белән Альфред бер-бер артлы өйләнгән. Әлегә бәбиләре юк. Әмма киленнәрнең игезәк бала сөясе килә, ди.

– Алия беренче туды. Аны «апагыз» дип әйтәм. Ул башкачарак. Ә менә малайлар бер-берсенә бик бәйләнгән. Хәтта сукыр эчәкләренә дә бер-бер артлы операция булды. Бер атна эчендә икесе дә хастаханәгә эләкте. Алар гел бергә, – ди ул.

Фәридә апаның Ринаты үз гаиләсен корган. Айраты – махсус хәрби операциядә. Әле менә ялга кайтып киткән.

– Баштарак кыен иде. Хәзер иләштек инде. Казанда эштә дип үземне юатам, – ди Фәридә апа. – Баланың һәркайсы газиз. Бер генә теләк – исән-сау булсыннар! Әти-әниләргә алар тормышына сөенеп яшәргә язсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Шөгыль

БӘҺАСЕЗ ХӘЗИНӘ

Чистай районының Каргалы авылына баргач, гап-гади бер ишегалдында тезелеп киткән хәрби машиналарга күзебез төште. Аларның хуҗасы Илгиз Гыймалетдинов та шушы тирәдә генә йөри иде. Хәрби машиналарның һәркайсы – 1940 нчы еллар автосәнәгать легендасы, төп модельләрнең төгәл күчермәсе. ГАЗ-69 йөк машинасыннан башланган коллекция, шактый тулыланып, бүген 12 хәрби техникага җиткән.

– Мин гомер буе гап-гади механик булып эшләдем. Яшьтән үк тимер-томыр эшен ярата идем. Сигез ел элек, пенсиягә чыккач, менә шушы коллекциямне туплый башладым. Сугыш, тарих темасы бик якын миңа. Анда катнашучылар – бик кадерле кешеләр. 1986 елда гаиләмне сугыш булган җирләргә алып бардым. Хатынь, Киев, Смоленск, Волгоград. Максатым – шушы машиналарны туплау һәм сугыш истәлекләрен яшь буынга тапшыру, – диде Илгиз абый.

Әлеге машиналарын ул каян күргән, ишеткән – шуннан алып кайтып, һәркайсына җан өргән.

– Болар – чын сугыш күргән тракторлар, – дип төртеп күрсәтте ул Харьков заводында эшләнгән тракторларга. – Үзебезнең республикада очраклы рәвештә генә күреп алып кайтканда, йөри торган хәлдә түгел иделәр. Мин аларны төзекләндереп, яңартып, ясап, буяп, йөрерлек хәлгә китердем. «Волга» машинасын да Горький автозаводыннан үзем алып кайттым. Анысы – көндәлек тормышта йөри торган төп машинам. Урамнан узганда, егетләр кул болгап, хөрмәт билгесе итеп, кул кыскан ишарә ясап калалар. Мин дә горур кыяфәттә кул изәп барам.

Әлеге хәрби машиналар белән ул Җиңү парадында, хәрби бәйрәмнәрдә катнаша. Җиңүнең 80 еллыгына ун машина белән чыгу турында хыяллана.

– Парадка чыгар алдыннан бик дулкынланам, төн йокламыйм. Бердән, горурлык булса, икенчедән, зур җаваплылык бит ул. Әле ярый рульгә утырырга һәрчак әзер торган дусларым бар. Аларга зур рәхмәт. Тик кайвакыт җитәкчелек кенә тиешле ярдәмен күрсәтеп бетерми, мондый техника узар өчен юлда шартлар тудырмыйлар. Аннан соң, авылыбыздагы һәйкәлнең яхшы хәлдә булмавы да борчый мине. Аны матур итеп, лаеклы итеп эшләсеннәр иде. Җиңү көнендә куелган венокларның бер-ике көннән соң юкка чыгуын да берничек кабул итә алмыйм, – диде Илгиз Гыймалетдинов.

Күптән түгел генә коллекциясенә тагын бер йөк машинасы өстәлгән. Россиядә нибары дүрт данә генә булган ЗИС-150 машинасы ул. Анысын да төзекләндереп, сафка бастырмакчы була оста.

– Ул машиналар Сталин идарә иткәндә чыга башлый. Сугыш вакытында төп машина була. Сталин үлгәч, аларның исемен ЗИС-164 дип алыштыралар. Бик сирәк экземпляр, аны яңарту буенча эш башланды инде, – диде ул.

Мондый саллы коллекциягә күпләр кызыга. Көн саен ук булмаса да, күп акча тәкъдим итеп, сатып алырга теләүчеләр бар, ди. Тик Илгиз абый өчен аларның һәркайсы – бәһасе булмаган хәзинә.

– Мине аңламаучылар да бар, – ди ул, ихластан елмаеп. – «Сиңа моның өчен нәрсә бирәләр соң?» – дип сорап куючылар да очрый. Тик мин моның өчен берни дә өмет итмим. Гаражымда бер буш урын да юк. Һәр киштәдә эш кораллары, запас частьлар ята. Аларның барысын сатып алыр өчен акча кирәк бит. Ләкин кызганыч түгел. Бөек Ватан сугышында 27 млн кеше яу кырында башын салган, 15 млн бала ятим калган. Без кулыбыздан килгәнне генә эшли алмаслык хәлдәмени? Әгәр мин дә, син дә бу эш белән шөгыльләнмәсәк, тарихны яшь буынга кем алып барып җиткерер икән соң?

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 338

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+